«Сүзгә килгәндә дәшми тору кирәк»

Алтын туйларын да уздырды алар, бриллиантын да гөрләтте. Быел менә гомер юлыннан иңгә-иң куеп атлауларына 70 ел була Насыйровларның. 70 ел бергә каршылаган гомер бәйрәменең ничек аталуын интернеттан чак эзләп таптым – куанычлы туй була икән ул. Туйлар белән бәйле түгәрәк даталар, гадәттә, 60 елдан соң – бриллиант туй белән чикләнә. Ярты гасырдан артык парлап яшәү сирәкләргә генә насыйп бәхет шул.

7 БИТ

Мирас: бүләк итәргәме, васыятьнамә язаргамы?

«Васыятьнамә һәм милекне бүләк итү – икесе ике нәрсә, алар хокукый яктан да, нәтиҗәләре буенча да аерыла. Мирасны бүләк итү турында сүз барганда, милек хуҗасы үзе исән чагында милкен икенче берәүгә кире кайтарып алмас өчен бирә. Бу очракта аның инде ул мөлкәткә бер катнашы да булмый. Ә васыятьнамәгә килгәндә, ул бары хуҗасы вафатыннан соң гына гамәлгә керә».

4 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри Казан

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 26.01.2017 | № 7 (5769)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

«ИКЕ КАТЛЫ АГАЧ ЙОРТ КҮЗ АЛДЫНДА КӨЛГӘ ӘЙЛӘНДЕ»

Янгын көндезге дүртләр тирәсендә чыга. Бу вакытта өйдә өч бала, хуҗабикә һәм аның энисе була. Бәхеткә, барысы да исән-сау. Тик менә хуҗабикә Арина Гафарова гына нык пешкән. Һөнәре буенча ул – мал табибы. Шуңа күрә йортның аскы катының бер өлешендә «Зоозащита»ның тәп пункты булган, биредә йорт хайваннарына ветеринария ярдәме күрсәтелгән. Янгын чыккан көнне дә монда унике эт һәм дистәдән артык песи яшәгән.

5 БИТ

КАЗ ИПИЕ

7 БИТ

МАРСЕЛЬ ВӘГЫЙЗОВ: «ТӘНКЫЙТЬНЕ СИҢА БИТАРАФ КЕШЕ ӘЙТМИ...»

10 БИТ

РЕСПУБЛИКАДА

ЧАЛЛЫ

Чаллы шәһәренең 5нче дәваханәсендә мөселманнар һәм православие динендәгеләр өчен гыйбадәт бүлмәләре ачылган. Биредә ремонт ясалган, идәннәренә келәм җәелгән, кыскасы, барлык шартлар тудырылган. Мәсәлән, 1нче неврология бүлекчәсендә җиһазландырылган мөселман гыйбадәтханәсендә кыйбла билгеләнгән, Коръән, башка дини әдәбият булдырылган. Биредә тәһарәт алу, госел коену мөмкинчелеге бар.

ӘЛКИ

Кышкы чорда җәнлекләргә ярдәм итү өчен, Әлки районында билгеле бер урыннарда азык салып тору оештырылган. Районның аучылык җәмгыятьләре көздән җәнлекләр өчен 100 тонна бөртек, 40 тоннадан артык ашлык калдыгы, 600 пардан артык яфрак себеркесе, 10 тонна печән, күп итеп тоз әзерләгән иде, боларның байтагы файдаланылган инде.

МАМАДЫШ

Шимбә көнне сәгать 11дә креатив чара – «Sunny-ФЕСТ» чаналар фестивале уздырыла. Чараны Татарстанның аграр яшьләр берләшмәсе белән район башкарма комитеты оештыра. Фестивальдә катнашучылар үзләре ясаган чанада трассаны үтәргә, чананың презентациясен күрсәтергә һәм боз тавыннан аска шуып төшәргә тиеш була.

АЛАБУГА

Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы 25 гыйнвардан 29ына кадәр, Студентлар көне уңаеннан, студентларны музей күргәзмәләренә бушлай кертәчәк. Бу хакта музей-тыюлыкның матбугат үзәге хәбәр итә. Түләүсез керү билетына ия булу өчен студент билетын күрсәтү җитә.

АЗНАКАЙ

Азнакайның 5нче урта мәктәбендә «Буыннар диалогы» акциясе бара. Шәһәрнең чаңгы базасында 7 А сыйныфы укучылары әбиләре белән очрашкан. Әбиләр сабый чакларын искә төшереп, рәхәтләнеп таудан шуганнар, чаңгыда йөргәннәр.

ЧИРМЕШӘН

Чирмешәндә быел беренче тапкыр үткәрелгән ярминкәдә алтмышлап кеше үз товарын тәкъдим иткән, күбесе – ерактан килүчеләр. Яшел Үзәннән – сөт һәм ит ризыклары, Самарадан – алма, Чаллыдан – кием-салым, Кукмарадан – киез итекләр, Әлкидән балык алып килгәннәр.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

Рөстәм Миңнеханов:

Милләтара татулык – төп кыйммәтебез

Соңгы елда республикада җинаять эшләре сизелерлек кимегән. Аеруча фатир басу, урлау очраклары азрак теркәлгән. Кичә Татарстан эчке эшләр министры Артем Хохорин министрлыкның еллык эшчәнлегенә йомгак ясады. Коллегиядә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан прокуроры Илдус Нәфыйков та катнашты.

Эльвира МОЗАФФАР

Республиканың эчке эшләр системасында 15 меңгә якын хезмәткәр эшли. 2016 елда Татарстанның Эчке эшләр министрлыгы чираттагы үзгәртеп кору чорын узды. Нәтиҗәдә, министрлыкка федераль миграция хезмәтенең республика идарәсе һәм законсыз наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту хезмәте дә килеп кушылды. Былтыр, хокук сакчылары ярдәме белән, наркотикларга бәйле 3706 җинаять эше ачыкланган, 140 килога якын наркотик матдәләр законсыз әйләнештән алынган.

Экстремизм белән бәйле җинаятьләргә килгәндә, соңгы арада интернет челтәрләрдә алар аеруча күбәеп китте. «Радикаль һәм криминаль группировкаларны тыю юнәлешендә хокук саклау органнарына эшне көчәйтергә кирәк», – дип искәртте Рөстәм Миңнеханов. Август аенда Казанда Татар зиратында кабер ташларын җимерү белән бәйле вандаллык очрагы турында да язган идек. Президент бу вакыйганы да искә алды.

– Татар зиратында вандаллык фактын ачыклауның чарасын күрергә кирәк. Милләтара һәм конфессияара татулык – безнең зур кыйммәтебез һәм көндәшлеккә сәләтле өстенлегебез. Без беркемгә вазгыятьне какшатырга ирек бирмәячәкбез, – диде ул.

Министрлыкның эшчәнлегенә уңай бәя биреп, Президент кайбер тәкъдимнәрен дә җиткерде.

tatarstan.ru

– Бу ел да зур чараларга бай булачак. Хокук органнарына «Куркынычсыз шәһәр» комплексы чараларын кулланырга кирәк. Республика буенча куела торган видеокамераларны да арттыру нәтиҗәле. Алар җинаятьләрне ачыклаганда, хокук саклау хезмәткәрләренә оператив карарлар кабул иткәндә ярдәм итә, – диде Президент.

Артем Хохорин исә Рөстәм Миңнехановтан чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәген яңарту буенча ярдәм дә сорады.

– Тиздән Татарстанда булачак халыкара масштабтагы зур вакыйга – Футбол буенча дөнья чемпионатын исәпкә алсак, әлеге мәсьәләнең актуальлеге тагын да арта, – диде Артем Хохорин.

Коллегия утырышында «Татфондбанк» хакында да сүз кузгатылды.

– Полиция бүлекләренә «Татфондбанк»тан зыян күргән кешеләрдән 150 гариза кабул ителде. Хәзер аларны икътисади җинаятьләр белән эшләүче бүлек тикшерә. Әлегә бернинди процессуаль карарлар кабул ителмәде. Җинаять эше кузгатудан бигрәк, кертемнәрне клиентларга кайтарып бетерү мөһим. Полиция банкны санацияләү эшенә комачауларга теләми, – ди Артем Хохорин.

Шәһәр кәефе

РАВИЛ ХӘМИТОВ,
отставкадагы капитан:

– Хәрби хезмәткә 25 ел гомеремне багышладым. Барлык океаннарны һәм диңгезләрне кичтем, мин – 3нче рангтагы капитан. Туган шәһәрем Казан төшләремә керә иде. Балалар үз яннарына чакыралар. Ничә еллардан соң сагынып кайткан Казанымнан бер җиргә дә китмим, дим аларга. Җәйләрен рәхәтләнеп дачада ял итәбез, кишәрлекләрдә казынабыз. Казан читендә кечерәк кенә өй салып, балта-чүкеч белән шакылдап, яшәргә хыял да бар әле.

АИДА САФИНА,
пешекче:

– Киров районында туып-үстем. Безнең районда җәмәгать транспорты маршрутлары азрак, ишегаллары да төзекләндерүгә мохтаҗ. Үзебезнең милли ризыкларыбызны пешерергә яратам. Кызлар аш-су әзерләргә куркып тормасыннар, пешерә-пешерә остарасың ул. Бүгенге тормышыбыз Аллага шөкер. Кибетләр һәм базарлар тулы азык-төлек, җаның ни тели – шул бар. Ходай сәламәтлектән аермасын.

ВЛАДИМИР АКСЕНОВ,
пенсионер:

– Россия Президенты Владимир Путин белән Премьер-министр Дмитрий Медведев Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевнә, 80 яше тулу уңаеннан, бергәләшеп кабул иттеләр. Бу – дөньяда күрелмәгән матур үрнәк һәм дәрәҗә. Казанда Суконка бистәсендә татар балалары белән тәгәрәшеп уйнап үстек. Татарстанда милләтара һәм динара дуслык, татулык гомергә саклансын.

ЛАНДЫШ КДРАСОВА,
студент:

– Казан федераль университетына укырга керүемә чиксез шатланам. Тырышабыз инде, укыйбыз. Чувашиянең Батыр районыннан үзем. Көн саен кайтып йөреп булмый. Җырлый-җырлый чигү чигәм, бәйлим. Шулай күңелемне юатам. Сагыну хисләремне шигырь юлларына да салам. Татар эстрадасын яратам, шулай ук Һиндстан киноларына һәм җырларына гашыйкмын. Һиндстанны бер барып күрәсе килә.

ШӘРИФ ХӘЙБУЛЛИН,
пенсионер:

– Оренбург өлкәсеннән Казанга күченгәнемә – 25 ел. Алла боерса, быел үземә дә 75 яшь тула. Татарча бик үк яхшы белми идем, хәзер гел ана телемдә сөйләшәм. Татар булып та татарча белмәүчеләрне, сәхнәләрдән «мин – керәшен», «мин – мишәр», дип сәерләнеп кычкыруларны хупламыйм. Бөек татар милләтеннән без, моның белән горурланырга кирәк. «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар», дигән мәкальне онытмыйк. Васыять кебек ул. Бердәм булыйк!

ria.ru

Имтиханнар тау артында түгел

9-11 ел буе мәктәптә алган белемгә нәтиҗә ясый торган БДИ (Бердәм дәүләт имтиханы), ТДИлар (Төп дәүләт имтиханы) быел да килеп җитәчәк. Министрлар Кабинетында узган брифингта да 2017 елда Татарстанда чыгарылыш сыйныфларда дәүләт аттестациясен үткәрүдәге үзенчәлекләр турында барды сүз. Журналистлар алдында Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасарлары Илдар Мөхәммәтов һәм Гөлнара Габдрахманова чыгыш ясады.

– Быел 14 500 бала – БДИ һәм 34 500 тугызынчы сыйныф укучысы ТДИ тапшырачак. Узган ел имтихан бирүчеләрнең саны 16 500 һәм 34 000 нисбәтендә булды. Быел да, нәкъ былтыргы шикелле үк, 86 имтихан кабул итү пункты эшләячәк, аларга стационар металл рамкалар куелачак һәм онлайн трансляция алып барылачак, – диде Илдар Мөхәммәтов.

Ул сайлап алына торган имтиханнарга гариза бирү вакытының аз калып баруын да искәртте. 11нче сыйныфта укучылар 1 февральгә кадәр үзләренең булачак һөнәрләрен билгеләп, кирәкле имтиханнарны сайларга тиешләр. 9нчы сыйныфларның уйларга тагын бер ай вакытлары бар әле. Аларның гариза бирү вакыты 1 мартка кадәр. 11нче сыйныфларда ике имтихан: математика белән рус теле мәҗбүри. Тугызынчыларга дүрт фән мәҗбүри. Икесе: математика белән рус теле – һәркем өчен, калган икесен үзләре сайлый.

Министрлык вәкилләре әйтүенчә, быел, былтыргы белән чагыштырганда, әллә ни зур үзгәрешләр юк. Шулай да берничәсен белеп китү кирәк.

– Быел физика, химия, биология фәннәрендәге КҮМнда (контроль үлчәү материаллары) тест өлеше булмаячак. Тест инглиз телендә генә калачак. Мәктәпләр дә, укучылар үзләре дә бу хакта беләләр. Болай эшләү халык арасында «БДИ ул – тестлар» дигән ялгыш фикерне бетерергә ярдәм итәр, – диде Илдар Мөхәммәтов.

БДИ биргәнче, чыгарылыш сыйныф укучылары 7 декабрь көнне үк инде инша һәм изложение яздылар. Билге куелмаса да, зачет алмаганнар имтиханнарга кертелми. Андыйлар 3 май көнне кабат язып караячак. Быел имтихан кабул итү пунктларында контроль үлчәү материаллары шунда ук принтерлардан чыгарылып биреләчәк, имтиханнарга җәмәгать күзәтчесе булып педагогика һәм юридик факультетта белем алучы студентлар чакырылачак.

Узган ел укытучылар да БДИ биреп караганнар иде. Быел мондый мөмкинлек теләгән әти-әниләргә дә биреләчәк.

Гөлнара Габдрахманова имтиханнар вакытында булган кагыйдә бозу очракларына да тукталды. 2013 елда аларның саны Татарстан буенча 30лап булса, узган елда бары 4 очрак кына теркәлгән. Укучыларның берсе телефон, өчесе шпаргалка белән эләккән.

БДИ бирәсе юк дип башка фәннәргә игътибарны киметү булмаячак быел. Чөнки интернетта Россия мәгариф һәм фән министры Ольга Васильеваның: «Имтихан тапшырмаган барлык фәннәр буенча да укучыларның белемнәре тикшереләчәк. Бу элек тә булган, ләкин быел ул бар җирдә дә бер үк вакытта һәм һәркемгә мәҗбүри булып узачак», – дигән күрсәтмәсе бар.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

ТОП – 3

РОССИЯ Хөкүмәте рәисе Дмитрий Медведев 2017 елда төбәкләрдә авыл территорияләрен үстерүгә һәм юллар төзү-төзекләндерүгә федераль бюджеттан субсидияләр бирү турындагы карарларга кул куйды, дип хәбәр итә ТАСС.

2014-2017 елларга һәм 2020 елга кадәр авыл территорияләрен үстерү федераль максатчан программасы кысаларында, 2017 елда төбәкләр арасында барлыгы 6,8 миллиард сум акча бүленәчәк. Алар торак шартларын яхшырту, инфраструктураны төзекләндерү, җирле халыкның инициативаларына грантлар бирү кебек максатларга тотылачак. Авылларда иҗтимагый әһәмияткә ия объектларга авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү һәм эшкәртү объектларына юллар төзү-төзекләндерүгә 2017 елда 54 төбәккә федераль бюджеттан 8,3 миллиард сум бүленәчәк. Иң зур күләмдәге субсидияләрне Башкортстан, Татарстан һәм Удмуртия алачак.

2018 ЕЛДАН Россиядә кулланучылар кәрҗинендәге минималь азык-төлек тупланмасын яңа кагыйдәләр буенча исәпли башлаячаклар. Моның өчен Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының сәламәт туклану таләпләренә җавап биргән азык-төлек куллану нормалары буенча тәкъдимнәре исәпкә алыначак. Бу очракта анда ярма һәм кумәчләр азрак булып (елына бер кешегә 126 килограмм урынына 96 килограмма калдырылачак), яшелчә һәм җиләк-җимешләргә өстенлек биреләчәк (140 килограмм һәм 100 килограмм). Ит (58 килограммнан 73кә кадәр), балык (18,5 килограммнан 22гә кадәр) һәм сөт ризыкларын (290 килограммнан 325 килограммга кадәр) арттыру көтелә. Әлеге исәпләүләр эшкә сәләтле халык өчен билгеләнгән, ә пенсионерлар һәм балалар өчен алар берникадәр кимрәк.

Россиядә минималь азык-төлек тупланмасын, шулай ук көнкүреш товарларын һәм хезмәтләрен үз эченә алган кулланучылар кәрҗине биш елга бер тапкыр карала.

ТАТАРСТАНДА социаль ярдәм алу өчен гаризаны электрон юл белән бирүчеләр саны 1 333 172гә җиткән. Шуны да әйтергә кирәк, алты яшькә кадәр балалары булган ишле гаиләләргә дарулар өчен субсидия түләү; күп балалы гаиләләрдәге балаларга юл хакы өчен субсидияләр; күп балалы гаиләләргә торак-коммуналь хезмәт өчен түләүгә субсидияләр; балалар бакчасына йөргән өчен компенсация; физик мөмкинлекләре чикләнгәннәргә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташламалы субсидияләр билгеләү; балага айлык пособие билгеләү; пенсионерларга бер тапкыр бирелә торган юл хакын билгеләү хезмәтләре тулысынча электрон вариантка күчерелгән.

Беренче рәсми коллектор агентлыгы

Татарстанда беренче рәсми коллектор агентлыгы – бурычларны кайтарту буенча «Редут» фирмасы теркәлде, дип хәбәр итә Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе матбугат хезмәте. Фирма Казанның Яхин урамында урнашкан. Исегезгә төшерәбез, 2017 елның 1 гыйнварыннан коллекторларга чикләүләр кертүче федераль закон үз көченә керде. Әлеге бизнес белән Суд приставлары федераль хезмәте реестрына кертелгән оешмалар гына шөгыльләнә ала.

Илшат Рәхимбайның фильмнары тәкъдим ителде

Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «HAVA Projects» медиа-компаниясе тарафыннан төшерелгән «Представь!» һәм «Не верю» фильмнары күрсәтелде (режиссеры – Илшат Рәхимбай).

«Представь» фильмы мулла һәм атакай арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтли, дин чикләре, чын Алланы, үзеңне эзләү хакында сөйли. «Не верю!» фильмы кешенең мәхәббәт хакына нәрсәләргә сәләтле булуы хакында.

– Бүген сез экранда күрсәтелгән фильмнарга без бөтен күңелебезне салып эшләдек. Әлеге вакыйга безнең тормышыбызда бик мөһим, ул күңелләребездә озак вакыт сакланыр. Бу процессның никадәр авыр булганын аңлаган кешеләр тагын да көчлерәк кул чапкандыр, – диде премьерадан соң режиссер Илшат Рәхимбай.

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Мирас: бүләк итәргәме, васыятьнамә язаргамы?

Мирас мәсьәләләре буенча редакциябезгә еш мөрәҗәгать итәләр. Укучыларыбыз соравы буенча, васыять итү, мирас итеп калдыру үзенчәлекләре турында «Татарстанның Нотариаль палатасы» ассоциациясенең башкаручы директоры Антон ШИБАЕВ белән сөйләштек.

Эльвира МОЗАФФАР

– Закон нигезендә мираска кемнәр дәгъва кыла ала?

– Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 1142нче маддәсе нигезендә закон буенча мираска, беренче чиратта, милек хуҗасының балалары, тормыш иптәше һәм әти-әнисе өмет итә ала.

– Редакциябезгә мөрәҗәгать иткән бер укучыбыз: «Фатирыбыз ирем исемендә иде, ул үлеп киткәч, кызым белән генә калдык. Иремнең туганнары, бу фатирда әнинең дә өлеше бар, дип, торакка дәгъвалый башладылар. Закон нигезендә бу шулай каралганмы?» – дип сорый.

– Әйе, тагын бер кат кабатлап әйтәм, закон нигезендә, милек хуҗасының әти-әнисе дә хатыны, балалары кебек үк бер дәрәҗәдә мирасчы булып санала (бары үз әти-әнисе генә). Ә менә милек хуҗасының ире яки хатынының әти-әнисенең торакта өлеше юк.

– Мирасны кемдер васыять (завещание) итеп калдыра, кайберәүләр дарственный ясата, ягъни бүләк итә. Кайсысы отышлырак?

– Кем өчен ничек инде. Моны һәркем үзе хәл итә. Васыятьнамә — гражданнарның үзе исән вакытта милкен мирас итеп тапшыру турында язып калдырган теләге, үтенече. Васыятьнамә һәм милекне бүләк итү – икесе ике нәрсә, алар хокукый яктан да, нәтиҗәләре буенча да аерыла.

Мирасны бүләк итү турында сүз барганда, милек хуҗасы үзе исән чагында милкен икенче берәүгә кире кайтарып алмас өчен бирә. Бу очракта ул бүләк иткән мирасыннан колак кага, аның инде ул мөлкәткә бер катнашы да булмый. Бүләк иткәндә, ягъни дарственный ясатканда, Росреестр органнарында дәүләт теркәве узарга кирәк. Теркәлү ун көн эчендә башкарыла. Ә васыятьнамәгә килгәндә, ул бары хуҗасы вафатыннан соң гына гамәлгә керә. Алты ай узгач кына мираска хокук турында таныклык тапшырыла. Васыять очрагында мирасчының эшкә яраксыз булып саналган тормыш иптәше, балигъ булмаган балалары, әти-әнисенә дә өлеш бүленергә тиеш.

– Кеше, торагын башка берәүгә васыять итеп калдыргач яки бүләк иткәч, үзе мөлкәтсез кала дигән сүзме?

– Бүләк итү вакытында нәкъ шулай. Әгәр кеше бүләк иткән торагында алга таба да яшәргә кала икән, яңа хуҗа аны теләсә кайсы вакытта куып чыгарырга, күченергә мәҗбүр итәргә хокуклы. Шуңа да бүләк итү эшләрен рәсмиләштергәндә сак булырга кушабыз. Бүләк итү процессын кире үзгәртүе бик авыр икәнен дә истән чыгармаска кирәк. Бары тик бүләк алучы дарственный ясаткан кешенең гомеренә куркыныч тудырса, зыян салса гына суд ярдәмендә килешүне өзәргә була. Васыятьнамә вакытында исә мирас хуҗасы үзе исән чакта мөлкәтен теләгәнчә куллана ала, шулай ук мирас итеп тапшыру турындагы күрсәтмәне дә үзгәртә, төзәтә ала.

– Дарственный ясатканда 13 процент салым түләргә туры килә дип ишеткәнем бар. Аны кем түли?

– Россиянең Салым кодексы нигезендә (217нче маддә), күчемсез милек, транспорт, акция, пай өлешләре бүләк итеп бирелгәндә кабул итеп алучы мирасчының якын туганы булмаса, мирас бәясенең 13 проценты күләмендә салым түләргә тиеш. Әгәр бүләк итүче белән кабул итүче арасында туганлык җепләре тыгыз икән (әти-әни, әби-бабай, апа-сеңел, абый-эне, ир-хатын), мондый очракта алар салым түләүдән азат ителә.

– Васыятьнамә, мирасны бүләк итү турындагы күрсәтмәне язганда нәрсәләргә игътибар итәргә кирәк?

– Васыятьнамә язу урыны һәм вакыты күрсәтелеп төзелергә һәм язучының үз кулы белән имза куелып, нотариус тарафыннан расланылырга тиеш. Васыятьнамә төзүченең үз акылында булуы мөһим. Кемгә күпме өлеш тиячәген, һәр пунктны ачык итеп, төгәл күрсәткәндә, өстәмә бәхәсләр килеп чыкмаячак. Дарственный ясатканда шулай ук барысы да юридик яктан дөрес рәсмиләштерелергә тиеш. Мирасның хуҗасы икәү булса, бүләк итүче кешегә икенчесеннән рөхсәт алу кирәк. Бүләк ителәсе йортта балигъ булмаган балалар яшәсә, балаларны опекага алу һәм попечительлек бүлегеннән рөхсәт кәгазе таләп ителә.

PS. Мирас калдыручы өчен васыятьнамә язу ышанычлырак кебек. Ә милекне кабул итүчегә бүләк ителгәнне алу отышлырак. Кыскасы, һәркем үзе өчен җайлысын, уңайлысын сайлый. Иң мөһиме – барысын да законлы, дөрес итеп башкарырга кирәк.

Киләсе тема: ПЕНСИЯ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ҮЗГӘРЕШЛӘР
Сәхифәбезнең киләсе санын пенсия өлкәсендәге үзгәрешләргә багышларбыз. Әлеге темага карата кызыксындырган, борчыган сорауларыгызны редакциябезгә **(843) 562-50-03, 8 (917) 851-69-62** телефоннары аша юллый аласыз.

ПОЧТАДАН

Агачларны кисмәгез!

Кешеләрнең агачларны кискәненә аптырыйм мин. Бу зур гөнаһ ләбаса. Безнең Саба районы, Яңа Мичән авылында Корбан бәйрәме көнне йөз еллык талларны аудардылар. Шул чакта ут чыбыклары өзелеп, авылда утлар сүнде. Телевизордан Корбан бәйрәме чарасыннан туры трансляция бара иде, аны да карый алмадык, догалар тыңлый алмый калдык. Район үзәгенә баргач, бер-бер артлы 92 төп агач киселгәнне күреп, исләрем киткән иде. Шул чакта ук юньлегә түгел бу, нидер булыр, ахры, бу дөньяда бернәрсә дә очраклы түгел, Ходай Тәгалә һәрчак безгә хәбәр бирә, дип уйлап куйдым. 25 декабрь көнне Кара диңгезгә Ту-154 очкычы егылып төште. Әлеге самолетта да нәкъ 92 пассажир иде бит. Без тәүбәгә килергә тиеш.

Резидә МИҢНЕБАЕВА,
Саба районы, Яңа Мичән авылы.

Мунча кирәк

Яңа Савин районында яшәүчеләр элек-электән җәмгыять мунчасына мохтаҗ. Җитәкчелек белән очрашулар булганда да бу теманы күтәрми калмыйлар иде. Ниһаять, 2013 елларда боз урыныннан кузгалгандай булды. Мунча булачак урын билгеләнде, өч ел эчендә ул өч катлы булып төзелеп тә бетте. Йортка «Банно-оздоровительный комплекс» дигән элмә такта да куйдылар.

Беркөнне мин дә яңа мунчада юынып кайтыйм әле дип, себеркемне кыстырып бардым. Мунча ишеге төбендә минем кебек дүрт ир-ат басып тора, мунча бикле. Дөрес, бина эчендә ут күренә. Баксаң, мунча эшләми икән. Ишекне шакыгач, бер ир-ат чыгып:

– Мунчаның хуҗасы юк, ул сатыла, сатып алучы табылганчы, мунча кереп булмаячак, –дип аңлатты.

Мунчада парланып булмады. Казанда 15ләп җәмәгать мунчасы бар иде. Хәзер алар бармак белән генә санарлык, кайсы сүтелде, кайсы үзгәртелеп төзелде, кайберләре шәхси кулларга күчте. Бәясе кыйммәт булгач, гади халык мунчага сирәк йөри хәзер. Казандагы җәмәгать мунчасында, гомуми залда юыну уртача 250 сум тора. Пенсионерларны ташлама белән 200 сумга кертәләр. Шуңа да күбебез өйдәге ваннада гына «парланырга» мәҗбүр. Кызганыч, кайбер коммуналь фатирларда юыну бүлмәләре дә юк бит әле аның. Шәһәр кешесенә барыбер мунчасыз булмый инде.

Сөләйман ШАКИРОВ,
Казан.

СОРАУ-ҖАВАП

Танышларым арасында кальян тартучылар бар. Кальян – тәмәке түгел, аның зыяны юк, дип акланалар. Чынлап та кальянның куркынычы юкмы, ул бәйлелек китереп чыгармыймы?

Азат ГАТИН,
Казан.

Рамил ГАРИФУЛЛИН, психолог, психотерапевт:

– Тәмәке, электрон сигаретлар кебек үк, кальян кешедә бәйлелек уята. Санап кителгәннәр арасында кальян – сәламәтлек өчен иң куркынычы. Аның төтене кешегә яшерен төстә һөҗүм итә, зарарлы матдәләр организмга үтеп керә, төрле авырулар китереп чыгаруы да бар. Кальянны күп илләрдә тыйдылар. Бездә дә чикләүләр кертелергә тиеш дип саныйм. Тәмәке, кальян, электрон сигаретлар – болар барысы да бизнес. Кешелеккә зыян китерә торган мондый кәсеп ярдәмендә табыш алу – зур гөнаһ, минемчә.

Whatsapp мессенджеры аша көне-төне килеп торган хәбәрләрнең кайсының чын, кайсының ялган булуын да белеп бетерә торган түгел. Шуңа күрә Казанның Привольный бистәсендә алты кешелек гаиләнең йортлары тулысы белән янып беткән һәм алар ярдәмгә мохтаҗ, дигән хәбәр килеп ирешкәч тә, ышанырга да, ышанмаска да белмәдем. Шулай да әлеге мәгълүматның дөреслеген тикшереп карау нияте белән, гаилә башлыгы Алексей Кляшевның кесә телефонын җыйдым. Чыннан да, шулай икән. Һәм әлеге фаҗига турында тулырак мәгълүмат алыр өчен, без Привольный бистәсенә юл алдык.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

«Күп вакытыбыз приюттагы йорт хайваннарына ярдәм күрсәтеп узды, шунлыктан шәхси әйберләребезне бөтенләй алып чыга алмадык», – ди хуҗа кеше.

Алексей КЛЯШЕВ, *башкалар да алар хәленә тарымасын дип, йорт салганда берничә киңәшне истән чыгармаска өнди:*

- **Агач йортны, һичшиксез, янгынга каршы чаралар белән бик яхшылап эшкәртергә кирәк. Моңа берничек тә акча кызганырга ярамый. Бу гамәл янгыннан тулысы белән сакламаса да, шактый вакыт утка каршы торырга ярдәм итә.**
- **Йорт салганда пластик материаллардан файдаланмаска тырышыгыз. Утта эреп, ул коточкыч төтенли, эшләргә комачаулый.**
- **Аннан соң электр чыбыкларын ялгауны да бары тик белемле һәм тәҗрибәле белгечкә генә тапшырырга кирәк!**
- **Йорт-җирләрне иминиятләштерергә дә акча кызганмагыз!**

«Ике катлы агач йорт күз алдында көлгә әйләнде»

Зөһрә САДЫЙКОВА

Янгын вакытында өйдә өч бала да була.

БӘЛА АЯК АСТЫНДА

Бәла агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри, диләр. Әлеге гаиләгә дә бәла көтмәгәндә ишек кага.

– Мин үз эшләрем белән Казанга чыгып киткән идем. Иптәшем Арина да минем белән бакчага барасы иде, әле ярый ул өйдә калган. Бергә чыгып киткән булсак, балалар белән ни булып бетәчәге турында уйларга да куркыныч. Янгын электр чыбыкларының кыска ялганышы аркасында килеп чыккан булырга тиеш, диделәр. Ул көнне бистәдә яшәүчеләрнең барысының да утлары уйнаклаган. Безнең өйдәге янгын да компьютер тирәсеннән чыккан. Ике катлы агач йорт күз ачып йомганчы янып көлгә әйләнде, – ди йорт хуҗасы Алексей Кляшев.

Янгын көндезге дүртләр тирәсендә чыга. Бу вакытта өйдә өч бала (кечкенә уллары Максимга – 9, кызлары Таисага – 10, өлкәннәре Данилга – 15 яшь), хуҗабикә һәм аның әнисе була. Бәхеткә, барысы да исән-сау. Тик менә хуҗабикә Арина Гафарова гына нык пешкән. Һөнәре буенча ул – мал табибы. Шуңа күрә йортның аскы катының бер өлешендә «Зоозащита»ның төп пункты булган, биредә йорт хайваннарына ветеринария ярдәме күрсәтелгән. Янгын чыккан көнне дә монда унике эт һәм дистәдән артык песи яшәгән.

– Үзебезнең өч песиебез бар иде. Без беренче чиратта – балаларны, аннан соң хайваннарны коткардык. Әмма алар кеше кебек тик кенә басып тормый бит, кайсы кая йөгермәкче була, янгын сүндерүчеләргә дә комачаулык иттеләр. Күп вакытыбыз аларга ярдәм күрсәтеп, тынычландырып узды, шунлыктан йорттагы шәхси әйберләребезне бөтенләй алып чыга алмадык. Хайваннар да җан иясе бит, аларны ничек итеп ут эчендә калдырмак кирәк? Алай да бер песиебез янган, берничәсе югалган, шуңа йөрәк әрни. Хуҗаларына ни диеп җавап бирермен? Алар аңлар, әлбәттә, әмма минем җаным барыбер тыныч түгел. Хуҗалары йорт хайваннарын балаларны яраткан кебек ярата бит, – ди Алексей.

Шунысы кызганыч, Кляшевлар йортларын иминиятләштермәгән булган. Йортны төзи башлаганнарына ун ел үткән, әле һаман да эшләре ахыргача бетмәгән булган.

ТАМЧЫДАН КҮЛ ҖЫЕЛА

Әлеге вакытта гаилә туганнары, якыннары янында яшәп тора. Балаларның мәктәпләре ерагайган. Шуңа да киләчәктә мәктәпкә якынрак җирдән фатир арендалап торырга уйлыйлар.

– Киләчәккә планнар – аякка басарга! Ярдәм итәргә теләүчеләр дә күп. Акчалата булыша алмаганнар, эш белән ярдәм итәбез, дип торалар. Янгыннан калган хәрабәләрне дә җыештырышырга килергә теләк белдерүчеләр күп. Безнең кайгыны шушы кадәр кеше уртаклашыр дип уйламаган идем. «Зоозабота» оешмасына, күршеләргә, туганнарга, дусларга, элеккеге хезмәттәшләргә бик зур рәхмәт, – ди Алексей.

Шулай да, бер яктан, кешеләрнең киң күңеллелеге, ярдәмчеллеген тойсалар, икенчедән, битарафлык белән дә очрашканнар.

– Янгын сүндерә торган машиналар тиз генә килеп җитә алмады. Чөнки алар уза торган кыска юлга кешеләр бетон блоклар куйган булып чыкты. Шунлыктан янгын сүндерүчеләргә урап узарга туры килде. Аннан соң тиешсез урында торган машиналар да комачаулады. Инде килеп җитеп, янгынны яхшы гына сүндерә башлаганнар иде. Беренче катны коткарып калып булыр, бәлки, дигән өмет тә уянды хәтта. Әмма янгын сүндерүчеләрнең сулары бетте, андагы проблемаларны хәл иткәнче, шактый вакытны югалттык, – дип ачына хуҗа кеше.

Привольныйда яшәүче халыктан да бәлагә тарыган гаилә турында бары тик яхшы фикер генә ишеттек. Хәтта күрше бистәдә яшәүчеләр дә, берләшеп, «Сладкий дворик» кибетендә әлеге гаиләгә ярдәм итү пунктын оештырганнар.

– Искиткеч яхшы, ярдәмчел гаилә. Арина табиб булгач, бөтен бистә халкы аңа мөрәҗәгать итә. Хәзер инде кем ничек булдыра, шулай булышабыз. Аларның шундый хәлдә калулары бик кызганыч, – диде безнең каршыга чыккан бер төркем халык.

Хөрмәтле газета укучыларыбыз! Әгәр әлеге гаиләгә ярдәм итәргә теләгегез булса (акчалата, кием-салым, көнкүреш кирәк-яраклары һәм башкалар белән), тулырак мәгълүмат алыр өчен редакциянең **(843) 562-50-12** телефонына шалтырата аласыз. Бәлагә юлыккан гаиләгә ярдәм кулы сузып, хәлләрен аз булса да җиңеләйтә алсак иде.

Озын гомернең сере – сабырлыкта

Кама Тамагы районының Кыртапа авылында туып, бүгенге көндә кызы Наилә белән Казанда яшәүче Нурлыбанат Нигъмәтҗановага 101 яшь тулган. Якыннары аның озын гомерле булуын сабырлыктан күрә.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Әниебез бик тә сабыр, ипле, тыйнак кеше. Бик күп авырлыклар-михнәтләр күреп яши-яши, шул сабырлыгы, тырышлыгы белән кыенлыкларны җиңәргә өйрәнгәндер инде ул. Ике яшендә – әнисез, ә биш яшендә әтисез калган. Ятимәне әтисенең энесе Хәйретдин белән аның җәмәгате Таифә тәрбияләп үстерә. 13-14 яшендә чагында ук торф чыгаруда, урман кисүдә катнашкан. Укыйсы килү теләге дә көчле була, гарәп язуын да, латин хәрефләрен дә өйрәнә. 18 яшендә күрше Апас районының Борнаш авылыннан Гаделҗан исемле егеткә кияүгә чыга. Авылда ачлык, шуның өстенә бер-бер артлы каенанасы белән каенатасы да дөнья куя. Башка бик күпләр кебек, әниемнәр дә читкә чыгып китә. Донецк өлкәсенең Макеевка шәһәрендә төпләнеп калалар. Бу кырыгынчы еллар була, – дип сөйләде безгә Наилә апа.

Тиздән Бөек Ватан сугышы башлана, әтиләре Гаделҗанны сугышка алалар. Әниләре өч яшь баласы белән үзе генә кала. Беркөнне алар яшәгән җиргә немец гаскәрләре килеп керә. Алар юлларында очраган һәр өйне яндыра башлый. Алты яшьлек Фәүзелҗан – кулына ипи, өч яшьлек Наил мендәр алып, күршеләр белән траншеяга качалар. Әниләре яшь бала белән өйдә кала. Чоланда торган салам өеменә бер немец ут төртә. Икенче берсе мәрхәмәтле кеше була, яшь балалы хатынны янып торган өйдән алып чыга. Нурлыбанат апа бер әчке күлмәктән генә кала. Аңына килгәч, улларын эзли башлый. Җиде көн эзләгәннән соң гына таба аларны. Кызганыч, яшь баласы үлә. Сугыш беткәч, балаларым чит-ят җирләрдә үсмәсен дип, туган авылына кайта. Бу вакытта Хәйретдин агасы үлгән була. Таифә апа аларны үз яннарына сыендыра.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

– Ул безнең өчен дәү әни булды, бик тату, матур яшәдек, – ди Наилә апа.

Нурлыбанат апа гомер буе колхозда эшли, бөтен авылга тегү тегә.

– Эшсез торырга бер дә яратмады. Бер минут вакытын да әрәм итмәс иде. Кеше кереп, озаграк сөйләшеп утырырга туры килсә дә, бу арада күпме эшемне эшли идем, дип уфтанганы әле дә хәтердә. 87 яшендә дә печән чаба иде. Әле хәзер дә: «Тик кенә утыра алмыйм, энә бир әле кулыма», – дип сорый. Ашарга пешерә башласам, бәрәңге, суган әрчеп куя. Озын гомерле булуның серен мин аның ризыкны озак чәйнәвендә дә дип беләм. 80 кат чәйнәргә кирәк, ди. Моны кайчандыр укытучылары Сөнгатулла абый әйткән булган. 95 яшенә кадәр ураза тотты, ә намазын әле дә калдырганы юк. 48 яшендә намазга басты. 100 яшенә кадәр Коръән укыды. Хәзер күзләре начар күрә, мин укыганны тыңларга ярата. Буш вакытларда: «Кызым, Коръән укыйк әле», – ди. Дисбесен дә кулыннан төшергәне юк, – ди кызы.

Нурлыбанат әбинең уллары гүр ияләре. Бердәнбер кызы гына исән-сау. Алты оныгы, унике оныкчыгы бар, аларның да балалары үсеп килә. Күптән түгел генә туган оныгының кызына, әбиләре кебек дин юлыннан китсен дип, Исламия исеме кушканнар.

Килене Рабига апа да аны мактап туя алмый.

– Балаларны тәрбияләргә булышты, сабырлыгы белән безгә үрнәк булды. Беркем белән сүзгә килмәде, гайбәтне яратмады, бөтен булганына шөкер итеп яши белде. Әниебез бик кунакчыл кеше, кунаклар ярата. Һәрчак якты йөзле, ягымлы сүзле, ачык күңелле булды, – ди ул.

Нурлыбанат әби авылда килене белән 48 ел яшәгән.

– Әниле-кызлы кебек тату тордык. Киленемнән мин бик разый. Шөкер, Аллаһы Тәгалә миңа бәхетле картлык бирде. Кызым, киленемнең, оныкларның ярдәмен тоеп, күңел тынычлыгы табып, өйнең түрендә булып, кадер-хөрмәттә яшим, – ди гасыр яшьтәше Нурлыбанат әби.

Быелның гыйнвар аенда Саба районының Оет авылында яшәүче Хәкимә Закировага, Кама Тамагы районыннан Халисә Сөләйманова белән Евгения Сафоновага, Биектаудан Фәйзрахман Әхмәтҗановка 100 яшь тулды. Апаста гомер кичерүче Зәйнәп Ибраһимова исә 103 яшен каршылады.

Тамак хәтере

Ничектер шулайрак килеп чыкты – берара акча бетеп китте. Бөтенләй. Кич эштән кайтканда берәр нәрсә алыйм дип кибеткә керсәм, кесәдә барлыгы бер ун тәңкә акча калган. Җитмәсә өздереп ашыйсы килә. Кердем өйгә. Суыткычтан ниндидер калдык-постыклар табып, калган ике йомырканы кыздырып ашадым. Туймады тамак. Ач килеш диярлек йокларга яттым.

Ач карынга яхшы уйланыла бит ул, ул кичне уйларым гел шул тамак тирәсендә булды. Иртәгәсен акча мәсьәләсен җайладым, тик менә ашамыйча яткан төн ничектер бәгырьгә кереп калды. Күп кенә нәрсәгә башкача карый башладым кебек. Шул ук өлкәннәр сөйләгәнгә дә. Тагын бер нәрсәне аңладым – бу яшәештә, әллә нәрсә дисәк тә, беренче чиратта тамак тук булу кирәк икән. Калганы – икенчеөченче чиратта, кем әйтмешли...

Әбием – мине үстергән Сылу карчык, яшьли әнисез калган. Бабай гайрәтле кеше, ялгыз гына яшәмәгән, әлбәттә, яшь хатын алып кайткан. Кияүгә чыкканы булмаган, бәбәй тапмаган Гадилә исемле ул үги ананың усаллыгы турында безнең гаиләдә легендалар йөри иде. Үги үги инде, шактый кыерсыткан ул үги балаларны. Әби сөйләгәннәрне тыңлаганда, чәчләр үрә торып иде. Ләкин ни булса да, гомере азагына кадәр әбекәй ул Гадиләне ихтирам белән искә алып яшәде. Сәбәбе – 1921 елгы ачлык галәмәте.

– Егерменче елның җәендә, безне – җиде-сигез яшьлек сабыйларны, Гадилә иртән кояш чыкканчы ук уята башлады. Йокы туймаган, торып булмый, тик аны тыңламыйча кара син! Торгыза да авылдан биш-алты чакрымдагы кырга алып китә. Көне буе алабута уябыз. Куллардан кан тама, тик Гадилә туктаттырмый. Көне буе алабута уып кайткач, ул аны өйдә җилгәрә дә, орлыгын чүлмәкләргә тутырып, өстенә элпә генә бал агызып, баз эчендә казылган базга төшереп куя. Һәм көн саен шулай. Арыдык, йончыдык, тик көзгә кадәр диярлек алабута уарга йөрдек без Гадилә белән. Нигә кирәген дә аңламыйбыз, чөнки әле көзләргә кадәр ашау белән андый авырлыклар булмады кебек. Ә аннан 1920-21нең кышы җитте. Авылда ачлык башланды – ашарга берни юк. Кышын урамнар иртәнгә ачка үлүчеләр мәете белән тула иде. Күрше авылларда үз балаларын ашаучылар да булды дип сөйлиләр иде. Ә без – ач булмадык. Гадилә, көн саен, әрли-әрли булса да, өчебезне дә тезеп утырта иде дә шул без җыйган алабута орлыгыннан әзерләнгән берәр ризык белән «сыйлый» иде. Алабута күмәче дә пешерде, боткасын да. Кышларны тук булып, исән-имин чыктык...

Әби шулай сөйли иде. Гадиләкарчыкка ихтирам да шул ел истәлегә икәнен аңлыйм хәзер. Чөнки тамак кайгысы – иң истә кала торганы инде ул.

Соңрак килгән буын – әтиләр буыны истәлекләре дә истә. Елга буеннан, язгы ташу чорында черек бәрәңге җыйганнарын әрнеп искә алалар иде алар. Шул черек бәрәңгедән пешерелгән кәлҗемәне хәтерлиләр иде.

«И-и-и, берәр заман, тамаклар икмәккә туйса да, черек бәрәңге күмәче пешергәләрбез әле, дип сөйләшә идек», – диләр иде. Монысы да бәгырьләргә кереп калган тамак кайгысы, тамак хәтере... Искә төшерсәң, мондый нәрсәләрне күпләп искә төшереп булыр иде ул.

Әле яңа гына Балтач районына баргач, Арбор авылында гомере буе эшләп яшәгән, әле бүген дә тик тора белми торган Фәләхетдин ага Сәләхетдиновларга кереп, аның истәлекләрен сөйләшеп утырдык. Заманында Фәләхетдиннең әнисе Шода авылы урманына эшкә йөргән. Ун яше дә тулмаган Фәләхетдин, көн саен дистә чакрымлап диярлек араны үтеп, әнисен каршы алырга йөргәнен хәтерли. Каршы алырга баруның сәбәбе – әнисе, «балам килә» дип, иртән үзе белән урманга әбәткә дип алып киткән ризыгының бер өлешен, ашамыйча, кире алып кайта торган булган. Әнисенең куенында уылган бәрәңге кушып пешерелгән кечкенә ипи кисәге чыгарып биргәнен, шуны ашаганын бүген, 70 елдан соң да, бераз ачынып искә ала ул.

– Бар иде шундый көннәр, их, бер тапкыр тамагым туйса, ну эшләп тә күрсәтер идем мин, дип уйлый идем, – ди Фәләхетдин абый. – Тамаклар бермәлне туйды, шуңа гомер буе ат кебек эшләдек тә, эшлибез дә. Бүген оҗмахта яшәгән кебек инде...

Монысы да тамак хәтере. Ач кешегә берни кирәкми. Тамак туймаса, башка кайгы калмый. Җәмгыятьнең хәтерендә иң озак саклаңган еллар ул – ачлык еллары.

...Кулга акча кергәч, суыткычны ризык белән тутырып куйдым. Әнинең бәрәңге уңышына шатланганын да яхшы аңлыйм хәзер. Тормышта бик мөһим нәрсә тамак кайгысы икәнен аңлар өчен, бер-ике көн акчасыз тору җитте кебек үзе. Балтачтан кайтканда, Норма авылында урнашкан гади бер кафега кердек. «Алсу» кафесында өйдә әзерләгән кебек әзерлиләр, бәяләр арзан. Тик бу юлы инде монда да ничектер уйлап, сайлап кына, ашап бетерерлек итеп кенә алдым ризыкны. Ни дисәң дә, нинди матур сүзләр сөйләсәң дә, ач булсаң, – бу җирдә башка берни кирәкми икән. Хәер, шулай булуы табигыйдыр да инде аның. Бу безнең тамак коллары булуыбыздан түгел, ә яшәешнең шулай корылган булуыннан бит. Ходаем, ачлыклар язма инде. Бүген без башка – андый-мондый хәл булса, 21нче ел кебек көн булмас иде хәзер. Шуңа беренче чиратта тамак тук булсын. Калганы җайлана кебек аның...

Илфак ШИҺАПОВ.

«Сүзгә килгәндә дәшми тору кирәк»

Насыйровларның 70 ел бергә тату яшәү серләре

Алтын туйларын да уздырды алар, бриллиантын да гөрләтте. Быел менә гомер юлыннан иңгә-иң куеп атлауларына 70 ел була Насыйровларның. 70 ел бергә каршылаган гомер бәйрәменең ничек аталуын интернеттан чак эзләп таптым – куанычлы туй була икән ул. Туйлар белән бәйле түгәрәк даталар, гадәттә, 60 елдан соң – бриллиант туй белән чикләнә. Ярты гасырдан артык парлап яшәү сирәкләргә генә насыйп бәхет шул.

Эльвира МОЗАФФАР,
Казан–Кама Тамагы,
Чаллы

ГАЙНАН БАБАЙ МУСА ҖӘЛИЛНЕ КҮРГӘН

Гайнан бабай белән Фәүзия әби – Чаллы авылында бик абруйлы кешеләр. Авылда мәчет торгызу, клуб, мәктәп салдыру эшендә дә башлап йөргән алар.

– Күрше Апас районына Коръән ашына баргач, халыкның акча җыешып мәчет төзүләре турында ишетеп кайттым. Чаллыда элек булган мәчет Совет чорында ябылган. Авыл картлары озак еллар аерым йортларга җыелып намазлар укырга мәҗбүр иде. Кыскасы, апаслылар үрнәгендә, без дә, авылдашлар белән берләшеп, 1991 елда Чаллыда мәчет ачтыра алдык, – дип искә ала Фәүзия әби.

Ире хөрмәтенә мәчеткә «Госман улы Гайнан» дип исем бирәләр. Гайнан бабай озак еллар авылның мулласы да булып торган. Бүген дә, 93 яшендә булса да, догаларын калдырганы юк.

Мин килгәндә, Гайнан бабай телевизордан хоккей карый иде. Югары Ослан районыннан кызлары Гүзәлия дә кунакка кайткан. Фәүзия әби, бисмиллаларын әйтеп, чәй ясарга кереште.

– Менә ябалдашлы әрем суын эчеп кара әле, аннары бал кабып куярсың, күп авырудан дәва, ди, балаларым миңа шуны эчерә, – дип, Фәүзия әби дару үләнен сузды.

Башындагы чигүле калфагы, кулындагы асылташлы беләзекләре килешеп тора үзенә. Хатын-кыз, ничә яшьтә булса да, өйдә дә әнә шулай матур булып калырга, үз-үзен карап торырга тиештер ул.

Насыйровларның җиде баласы көн дә диярлек чиратлашып әти-әнисе янына кайтып йөри. Үзләре янына да алып китәрләр иде аларны, тик Гайнан бабай белән Фәүзия әби генә: «Нигезне ташламыйбыз», – диләр. Шөкер, әле үзләре, күз тимәсен, тавыклар асрыйлар, өй тирәсендә җай гына кайнашалар. Яңа ел алдыннан икәүләп пилмән бөккәннәр.

Гайнан бабай белән аның яшьлек елларын искә төшерәбез. Бу үзе бер китап язарлык тарих. Язмыш Гайнанны тугач ук сыный башлый. Сабыйга 40 көн булганда, әнисе үлеп китә. Бер елдан әтисе дә вафат була. Малайга өч яшь тулганда, аны Насыйровлар гаиләсе асрамага ала.

Гайнан бабай – сугыш ветераны. 1942 елда бер төркем фронтташлары белән дошман кулына әсирлеккә эләгә, «Идел-Урал» легионында була.

– Бу легион төрле милләт халыкларыннан төзелгән җиде батальоннан тора иде. Батальон җитәкчебез Шәфи Алмас башта ук: «Безнең алга бару өметебез юк. Иң мөһиме – үзегезне саклагыз», – дип кисәтеп куйды. Ачтан үлмәс өчен, без дә легионга кердек. Ашарга юк. Лагерьга кайту юлында чүплек тулы чокырлар очрый иде. Һәркем шуннан нәрсәдер эләктереп калырга ашыга. Лагерьга кайткач, табышны чистартабыз, запаска әзерләп куябыз. Ике батальон Көнбатыш Украинада сугышкан чакта, күп солдатлар партизаннар белән бергә үзебезнең якка чыгып беткәннәр. Ә безгә андый бәхет насыйп булмады. Немецлар корал бирмәде. Без окоп казыдык, күперләр сакладык, – дип искә ала ул елларны Гайнан бабай.

Легионда чакта, якыннан ук булмаса да, шагыйрь Муса Җәлил белән очрашкан булган ул. Бөек шагыйребезне әңгәмәдәшем горурлык хисләре белән искә ала. Фашист концлагерьларының коточкыч шартлары да Муса Җәлилнең рухын сындыра алмый. Ул иптәшләре белән «Идел-Урал» легионында яшерен оешма булдыра, шунда дошманга каршы көрәш алып бара. Татар, башкорт әсирләре өчен концертлар куябыз дигән булып, бик күп концлагерьларга бара, анда фашистларга каршы яшерен төркемнәр оештыра. Кызганыч, Муса Җәлил һәм җәлилчеләр: Гайнан Кормаш, Әхәт Атнашев, Абдулла Алиш, Сәлим Бохаров – барлыгы 11 татардан торган төркем 1944 елның 25 августында Берлиндагы Плетцензее төрмәсендә гильотинада җәзалап үтерелә.

Гайнан бабай да туган якларына 1947 елда гына кайта. Тракторчы һөнәрен үзләштерә. Бер урамда уйнап үскән Фәүзиягә өйләнә. Тормыш җайланды дигәндә генә, коточкыч хәбәр барлык хыялларны җимерә. Гайнан бабайны, халык дошманы дип, 25 елга төрмәгә ябалар. Сатлыкҗан ярлыгы тагылганнар, гаепсезгә ирекләреннән мәхрүм ителгәннәр өметен өзми – амнистия көтеп яши. Бары 1957 елны гына Гайнан бабай азат ителә.

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА, 70ЛӘП БУЛАБЫЗ

70 ел гомер. Насыйровлардан озак еллар тигезлектә, бер җан булып яшәүнең серләрен сорашам.

– Авырлыклар күп күрдек. Бергә кичергән кайгы-шатлыклар мөнәсәбәтләрне ныгыта. Гайнан чын ир-ат булды. Ямьсез сүзләр әйтмәде, кул күтәрмәде. Каенана, каената янында да ун ел яшәдек. Өлкәннәрнең киңәшләре дә ярдәм итми калмагандыр. Җиде бала тәрбияләп үстердек, – ди Фәүзия әби. – Тату яшәүнең иң мөһим кагыйдәсе – сабыр була белүдә. Сүзгә килгәндә дәшми тора белү кирәк. Авыр сүзләр әйтү яхшыга илтми. Бер-береңнең кадерен белеп яшәүгә ни җитә.

Ходай тарафыннан бирелгән тигез тормышның сере изге гамәлләрдәдер, мөгаен. Бөтен Чаллы авылы халкын су белән туендырган, өйдәге краннарга торба аша килгән чишмәне дә элек-электән Гайнан бабай карап торды. Хәзер аңа бөтен авыл ярдәм итә. Быел менә чишмәнең тирә-юнен яңартырга җыеналар. Төзелеш материаллары да кайтартылган инде.

Гайнан бабайның кулыннан килә: тимерче дә булган ул, туннар да теккән. Авылдашлары еш кына пыяла кистерергә, тегү машинасы төзәттерергә аның янына килә торган булган.

Насыйровлар апрель аенда булачак «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе әзерли торган «Пар канатлар» тапшыруының 30 еллык юбилеена да чакырулы. Гайнан абый белән Фәүзия апаның бүген 17 оныгы, 22 оныкчыгы бар. Барлык туган-тумачалар бергә җыелганда, 70кә җитә икән Насыйровлар. Әле менә балалары нәсел шәҗәрәләрен эшләү белән мәшгуль.

Кызлары Гүзәлия Гәрәева – татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

– Әти-әнине карау – төп бурычыбыз. Исән-сау гына булсыннар, – ди Гүзәлия апа.

Кадерлеләренә шигырь юллары да багышлаган ул:

Җирдә кояш нуры
балкыгандай,
Балкыйсыз сез
безнең күңелдә.
Тормышыбыз сезнең
белән матур,
Рәхмәтебез, сезгә –
гомергә.

Яз җиткәнен кызлардан бигрәк, әбиләр көтәдер. Тәрәзәләргә боз каткан, өй каршындагы коймa башына хәтле кар өелгән, ә әби, яз көне чыгачак каз бәпкәләренә дип, мичкә ипи сала.

Каз ипие

Кактырылмый гына тарттырылган арыш оныннан мич төбенә салып пешерелгән мондый ипине каз ипие дип атый халык. Бертөрле тәм салып пешерелмәсә дә, бала чакта мичтән алгач та, кырыйларын кетердәтеп ашый торган идек. Мәктәп елларында Ленинград блокадасындагы балаларның ачлык газапларын йөрәк аша уздырып үскән буын булгангадыр, бу түгәрәк чем кара икмәкне, күңелемнән генә, шул ачлыктан газапланган балаларга бүлә торган идем. Әгәр шул вакытта бу ипи булган булса...

Бу атнада авылга кайтсам, мич алдында каз ипиләре тезелеп тора. Әниемнең, әбиемнең кыш буе ипи әзерләгәннәре искә төште. Авыл халкының хәстәрлегеннән инде бу. Кыш көне барыбер мичкә ягасы, мичне тарткач буш калдырмассың ич инде. Кайсыдыр көнне үзенә дип ипиен, камыр ризыгын пешерсә, икенче юлы, әлбәттә инде, үзе белән бергәттән кош-кортын, терлеген дә кайгыртасы. Каз ипие суга колмак яки юеш чүпрә салып кына пешерелә һәм берәр көннән соң, телемләп, кабат мичкә тыгып киптерелә иде. Аннан соң инде капчыкларга тутырып тышка чыгарып куялар. Кирәк булганда шуны, салкын суга салып җебетеп, бәпкәләргә бирәсең. Җылы суда ул изелеп боткага әйләнә, бибиләргә ашарга уңайсыз була андые.

Бүгенге көндә авылда казларга дип махсус ипи пешерүчеләр бик сирәк. Әбиләр иренмәсләр иде анысы, тик газ кергәч, күбесе мичләреннән мәхрүм булдылар. Бик сирәк авыл өйләрендә генә ипи сала торган мичләр сакланып калды. Без ул яктан бәхетле, мин үскән төп йортта да, килен булып төшкән нигеземдә дә борынгы мичләр әле дә тора. Мич коймагын, мич бәлешен ашаудан мәхрүм түгел без. Бу нигъмәтләр турында тәфсилләп язар идем, онытылып китәрмен дип куркам. Әнекинең сүзләренә караганда, бер өй аша гына тагын бер гаилә каз ипие пешерә икән, икенчеләре кибеттән алып киптерәләр. Узган кыш кына аның белән ярышып казларга ипи хәстәрләүче Асия ахирие генә быел китеп барды, авыр туфрагы җиңел булсын.... Сиксәнне тутырган әбиебез көз көне: «Быел бәпкәләр, чебешләр алмыйм», – дип кырт кискән иде, аның кабат ипи әзерләвен күргәч, елмаеп куйдым. Күп тапкырлар бәпкәләр куганын күрергә язсын.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА.

Башларымда мамык шәл

«Шәһри Казан» десанты белән Балык Бистәсе районының Түбән Тегермәнлек авылына кайткач, бер төркем җырчыларның концертын карарга дип мәдәният йортына җыелган апалар барысы да башларына йомшак мамык шәл бөркәнгән иде. Шулай булмый ни, бу тирәдә яшәүче авыл халкы инде ничә буын шәл бәйләү осталыгын саклап, мамык шәл җылысын башкаларга да бүләк итеп яши бит!

Зөһрә САДЫЙКОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Балык Бистәсе районының тырыш халкы гомер-гомергә әлеге кәсеп белән тормыш көткән. Зур сабырлык, түземлек сорый торган һөнәр белән бүген дә шөгыльләнәләр. Шәмсенур апа Габитовалар гаиләсе дә әнә шундыйлардан.

– Шәл бәйләргә өченче сыйныфта өйрәнгән идем. Шуннан бирле мамыкның кулымнан төшкәне юк. Шәл, бияләй, оекбаш, шарф, башлык бәйләп сатабыз. Мин бәйлим, киленем Мәсфирә базарга алып барып сатып тора. Бер ай эчендә җиде кием бияләй, бер олы шәл, бер шарф, өч башлык, ике кием оекбаш бәйләдем. Мин өйдәге башка эшкә кул тидермим. Намазымны укыйм да бәйлим дә бәйлим. Авылыбызның һәр гаиләсендә дә шәл бәйли белүче бар, тик аларның күбесе сатар өчен түгел, ә үзләре өчен генә бәйли. Элегрәк кәҗә мамыгыннан бәйли идек. 70-80нче елларда гына сарык йонынан эшли башладык. Иң элек сарык йонын юып, «пәрәмәчләп» куябыз. Аның өстенә куян мамыгы салабыз. Аннан соң аны катыштырабыз. Киленем шапый тора, мин бер көн эчендә бәйләп бирәм, – ди 65 яшьлек Шәмсенур апа.

Шәмсенур ападан сыйфатлы, яхшы шәлне ничек тикшереп карарга мөмкин икәнлеген дә сораштым.

– Шәл бәйләгәндә иң мөһиме – мамыктан уңу, – диде ул. – Мамык сыйфатлы булса, шәл дә шәп булачак. Себер якларында шәлнең сыйфатын йөзек аша чыгарып тикшерәләр. Ләкин безнекеләрне алай эшләп булмый, чөнки алар калын. Ә Себер шәлләрен юка итеп, беренче чиратта матурлык өчен дип бәйлиләр. Безнең сыйфатлы шәлнең мамыгыннан тотып күтәреп карагач, ул өзелеп төшмәскә тиеш.

Яхшы шәлгә сорау да зур икән. Бер зур шәлне 3000-3500 сумга сатылар. Бәйләгән әйберләре беренче барганда ук сатылып бетмәгән очракта да, икенче юлы, һичшиксез, алып бетерәләр икән. Без аларга кергән көнне дә киленнәре бер ай эчендә бәйләнгән кул эшләрен сатарга дип киткән иде.

Габитовларның гаиләсе ишле. Шәмсенур апа тормыш иптәше Вазыйх абый һәм улларының гаиләсе белән бергә яшиләр.

– Бабаем белән гаилә коруыбызга – 45 ел. Өч бала тәрбияләп үстердек. Үзем, 15 яшь тулу белән үк, фермага бозау карарга кердем. 13 ел яшь бозаулар карадым, аннан соң сыерлар саудым. Барысы бергә фермада эшләгән елларым 39га тула. Үз эшемне намус белән башкардым, әмма бик аз пенсия белән чыгардылар, шуңысына бик рәнҗим. 40 елга якын авыр эштә эшләсәм дә, пенсиям җиде меңгә дә тулмый, – ди ул.

Әлеге тырыш, бердәм гаилә, шәлләр бәйләп сатудан тыш, терлекчелек белән дә шөгыльләнә. Үзләренең 20 гектар җирләре бар. Терлек азыгын шунда юнәлтәләр. Биш савым сыерының сөтен дә үзләре эшкәртеп, эремчеген, каймагын, маен саталар. Хөкүмәттән бирелгән субсидияне дә кушып, зур сарай тергезгәннәр.

– Бүгенге көндә сарайда атыбыз, сигез баш эре терлегебез, бозауларыбыз бар. Киләчәктә сыерларны тагын да арттырырга исәп бар. Башта балалар малны яхшылап ашатып үстерәләр. Аннан соң, азапланып, атнасына бер тапкыр Казан базарына барып, үзләре торып саталар. Җитмәсә, шуларга бер мең сум штраф та салалар. Малчылык белән шөгыльләнергә кушалар, тик менә шундый вакытлары күңелне төшерә, – дип ризасызлык белдерә яңа танышыбыз.

ШӘМСЕНУР ГАБИТОВАДАН ШӘЛНЕ ОЗАК САКЛАУ СЕРЛӘРЕ

Шәл озак хезмәт итсен өчен, аны көядән сакларга киңәш итә ул. Өч литрлы банкага яки исле сабын һәм көяне якын китерми торган башка чаралар, хуш исле үләннәр белән бергә пакетка салып сакларга була. Шәлне юарга туры килсә, башта тарап, бер төрле температурадагы суда юып чайкарга кирәк. Саргайган булса, водород перекисе салынган суда берничә сәгать тотарга һәм чайкарга киңәш ителә. Киптергәндә, әлбәттә, шәлне тарттырып киптерү мөһим.

Безнең әти – СУПЕР!

Ата. Әти. Бу сүзнең үзендә үк ниндидер ныклык бар. Чөнки әтиләр – һәр гаиләнең терәге, башлыгы, президенты. Без үзебезнең әтиләребез турында гафу итмәслек дәрәҗәдә аз сөйлибез, аз язабыз.

Әтиебез – олы йөрәкле, киң күңелле һәм бик шәфкатьле кеше. Үзе алыптай олы гәүдәле, киң җилкәле, пәһлеван кебек. Аның шәфкатьле, игелекле канаты астында безгә – барлык балаларына да җылы һәм бик рәхәт. Ә бит без аз да түгел, күп тә түгел, бер дюжина – 12. Биш батыр малай, җиде матур кыз һәм тагын бер нәни кызчык – онык Әмилә.

Әтиебез бик гадел дә, ягымлы да. Ул беребезне дә авыр сүз әйтеп рәнҗетми. Ә бит безнең уныбыз тормышның ачысын-төчесен күргән ятим балалар, холкыбыз да шикәрдәй, балдай түгел. Әтиебезнең куллары алтын. Узган ел ул безгә җәйге йорт һәм спорт залы төзеде. Машинаны да оста йөртә. Олы апабыз Миләүшәне дә машина йөртергә ул өйрәтте. Хәзер апабыз Казанда яши. Кунакка кайткан саен, әтигә рәхмәт әйтеп туя алмый. Хәзер әти Адел, Илья, Сашаны да машина йөртергә өйрәтә. һәр көнне эштән кайтканда әтиебезнең кесәсендә безнең өчен күчтәнәче, кулында әниебезгә чәчәкләр була.

Узган ел Анапада әтиебезнең курку белмәс кеше булуын да күрдек. Без ял итә торган корпуста янгын чыккач, әтием курыкмыйча, төтен тулган бүлмәләргә кереп, янгын сүндерүчеләргә булышып йөрде. Куркып елаган балаларны кочагына алып тынычландырды. Ул безне дә игелекле, ярдәмчел булырга, өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәтә. Бәйрәмнәрдә бергә җыелу да – әтиебезнең идеясе. Ул мондый көннәрдә төрле бүләк-күчтәнәчләр әзерләп, безгә көтелмәгән куанычлар ясый.

Без бөтен эшне дә бергәләп эшлибез, гаиләдә һәммәбез дә артистлар. Гаилә театры – «Вернисаж»ыбыз бар. Төрле конкурсларда катнашып, район, республика һәм хәтта Бөтенроссия дәрәҗәсендәге лауреатлар булдык. Театрның, бөтен тормышыбызның да нигезе – әтиебез. Ул кулына гармун алса, аякларыбыз үзеннән-үзе бии башлый, җырларга да күп сорамыйбыз.

Әтиебез эшне хатын-кызныкына, ир-атныкына бүлми. Әниебезгә аш пешерергә, кер юарга да, өй җыештырырга да ярдәм итә. Ул – суперәти! Пешергән ашлары, ясаган коймаклары, кыздырган бәрәңгеләре телеңне йотарлык тәмле була. Аның белмәгән бер генә эше дә юк. Максим белән Дима планшетлары ватылса, әтигә тотып киләләр, Милена белән Аделинаның курчакларының кулы сынса да, әти тиз генә төзәтеп бирә. Өйгә бирелгән мисал, мәсьәләләребез чишелмичә киреләнеп торса да, әтиебез бар. Ул безнең белән футбол да, хоккей да уйный. Җиңсәк, балаларча сөенә. Китап укырга да ярата, безне дә үз артыннан ияртә. Аның аяк киеме елның теләсә кайсы фасылында көзге кебек ялтырап тора. Бездән дә шуны таләп итә, һәрьяклап үрнәк. Җыеп кына әйткәндә, әтиебез Наил Рәшит улы Латыйпов дөньяда иң әйбәт, иң шәп әти! Без исә аның балалары: Миләүшә, Венера, Мария, Адел, Александр, Илья, Регина, Максим, Милена, Аделина, Дима, Әмилә – иң бәхетле балалар. Бу фикергә әниебез Рәйсә дә кушыла.

Латыйповлар – Миңнуллиннар гаиләсе.

Яшел Үзән районы,
Норлат авылы.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

1

2

3

4

5

6

7

8

9

10

Милли ашлар: әзәрбайҗан кухнясы

Әзәрбайҗан кухнясы башкалардан яшелчәләр белән пешерелгән итле ризыкларга бай булуы белән аерылып тора. Аларның күбесе махсус савытларда әзерләнә. Ипи урынына кулланыла торган чурекны – тандырда, питины – балчык чүлмәктә, пылауны – казанда, ә менә саджны шул ук исемдәге табада пешерәләр.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

УТТА ЯРАЛГАН РИЗЫК

«Хан Булак» рестораны шеф-повары Руслан Гурбанов белән без бүген кадерле кунаклар килгәч кенә әзерләнә торган саджны пешерергә булдык. Аны, икенче төрле, утта яралган ризык дип тә атыйлар. Ни өчен дигәндә, һәр ингредиент аерым-аерым табада кыздырыла, әзер саджны, табасы белән табынга чыгарганда, янып торган күмер салынган махсус савыт өстенә куялар. Шуңа ул озак суынмый тора.

Садж ясау өчен безгә 200әр грамм сыер ите, сарык ите, тавык ите, 200 грамм курдюк (сарык мае), дүрт зур шампиньон, бер зур болгар борычы, ике зур бәрәңге, ике помидор, бер баклажан, ике суган, үсемлек мае, тоз, борыч, тәмләткечләр кирәк була.

Русланның әйтүенчә, садж табасы урынына тирән булмаган киң таба да кулланырга ярый. Әлбәттә, тәме аз гына аерылып торачак. Башта табаны кыздырабыз да аңа кисәкләп туралган курдюк салабыз. Ул эри башлагач, аңа шакмаклап туралган өч төрле итне салып кыздырабыз.

– Курдюкны үсемлек маена алыштырырга кирәкми, шулай ук аны сарык итеннән башка да пешерергә киңәш итмим, саджның бөтен тәме дә шунда. Гомумән, без ризык әзерләгәндә күбесенчә сарык итен кулланабыз. Ышаныгыз миңа: сарык итен әзәрбайҗаннар кебек тәмле итеп пешерүче юк, – ди Руслан.

Шампиньонны дүрт өлешкә бүлеп, ит янына салабыз. Суганны саламлап турап, шулай ук ит өстенә салабыз да табаның өстен капкач белән каплап куябыз. Баклажан белән помидорны, бәрәңгене (кабыгын әрчемичә генә) түгәрәкләп, болгар борычын саламлап турыйбыз. Кызып торган ит өстенә тоз белән борыч һәм сумах дигән кызыл төстәге тәмләткеч сибәбез. Әлеге тәмләткеч ризыкка матур төс, хуш ис һәм үзенчәлекле тәм бирә. Тәме белән ул лимонны хәтерләтә. Аерым табада үсемлек маенда бәрәңгене ике яклап кыздырып алабыз. Аны алып куеп, шул ук табада баклажанны, аннары болгар борычын, соңыннан помидорны аерым-аерым кыздырып алабыз. Түгәрәк лавашны дүрткә бүлеп, аларны урталай бөклибез дә үсемлек маенда кыздырып алабыз. Яшелчәләр белән лавашны, петрушка ботакларын ит янына матур итеп тезәбез дә табаны күмер салынган махсус савытка утыртабыз. Аны һәр кеше үз тәлинкәсенә салып ашый.

– Әзәрбайҗан кухнясы белән якынрак танышасыгыз килсә, сезгә, һичшиксез, саджны авыз итеп карарга кирәк. Аның тәме тел очыгызда бик озак сакланачак, – ди шеф-повар Руслан.

Ул безгә довга дигән бик популяр кефирлы ашның рецептын да бирде. Аны салкын килеш эчемлек итеп эчәргә дә, кайнар килеш аш итеп тә ашарга була икән. Әзерләү өчен берничә минут вакыт җитә. Кефирга аз гына су, чи күкәй кушып утка куясың. Кайнап чыкканчы болгатып торасың. Аннары күп итеп яшел тәмләткечләр: кинза, укроп, шпинат, бөтнек турап саласың. Аерым тозлы суда пешкән нут борчагын саласың. Тоз, борыч сибәсең.

БАЛЛЫ ИЛ

Әзәрбайҗан үзенең пылаулары белән дә данлыклы. «Хан Булак» рестораны администраторы Турал Заманлы әйтүенчә, анда пылауның 120 төре билгеле.

– Безнең милли кухняда ул аерым урын алып тора. Бигрәк тә шах пылау дигәне популяр. Бер генә бәйрәм дә аңардан башка узмый. Шах пылау тышкы кыяфәте белән тортны хәтерләтә, чөнки дөге, ит, кипкән җимешләрне лаваш эченә тутырып пешерәләр. Әмма итне алдан кыздырып, дөгене суда пешереп алалар. Аннары лаваш эченә тутырып, газ мичендә пешерәләр. Дошама пылау да бар безнең. Ул тавык итеннән әзерләнә, – дип сөйли Турал.

Икмәкне Әзәрбайҗанда чурек дип атыйлар. Аны тандырда пешерәләр. Тандыр борынгы чорларда кояш символы булган. Шуңа да күмер өстенә су сибү аларда хупланмый. Учак үзе сүнәргә тиеш, күмерне суынганнан соң алып җиргә күмәләр.

Әзәрбайҗанның һәр районы үзенең ризыгы белән атаклы. Ленкорань шәһәре, әйтик, балык ризыклары белән, ә Шемахы камыр ризыклары белән атаклы икән. Шеки хәлвәсенең даны еракларга таралган. Аны Нәүрүз бәйрәменә махсус ясыйлар. Интернетта рецептлары булса да, чын хәлвәне Шекида гына ясый беләләр.

– Гомумән, Әзәрбайҗанның баллы ризыклары беркемне дә битараф калдырмый. Шакербура, пәхләвә, шор гогал, мутаки, бадамбура, курабье, кята, шекер-черек – аларның саны утызга җитә. Шуңа да күпләр Әзәрбайҗанны баллы ил дип атый. Чәйне исә бездә груша формасындагы пыяла стакан – армудка салып эчәләр. Ул чәйне озак суытмый тора. Чәйне чабыр (чабрец) үләне салып кайнатабыз. Кара чәйне бездә күбрәк эчәләр. Чәй янында һәрвакыт кайнатмалар була. Айва, инжир, кизил, әстерхан чикләвеге, карбыз кабыгы, роза чәчәге таҗларыннан да кайнаталар аны. Бакуга бара калсагыз, һәрберсенең тәмен татып карамый китмәгез, – ди Турал.

Марсель Вәгыйзов:

«ТӘНКЫЙТЬНЕ СИҢА БИТАРАФ КЕШЕ ӘЙТМИ...»

Марсель Вәгыйзов исеме күптән «колакта» булса да, аның белән моңа кадәр аралашырга туры килмәде. Эстраданың «капыл йолдызлары» белән аралашырга атлыгып торыр яшьтән узыбрак китүем дә сәбәп инде моңа. Тиз кабыналар, тиз байыйлар, тиз, тиз, тиз. Андый егетләр, кызлар белән сөйләшкәләгән бар-барын. Арада борыннарына чиләк элеп куйсаң, мәңге төшеп китмәслек итеп чөелгәннәре дә бар. Утырасың аннары диктофондагы язмадагы «иҗатым», «халкыма хезмәт итәм» ише сүзләргә шаклар катып. Сәхнәдә 5 ел – пафос 50 еллык.

Зимфира ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА

Югары даирәләрдә, купшы бәйрәмнәрдә чыгыш ясаучы, бер генә дәрәҗәле чарадан да калмаучы җырчы Марсель Вәгыйзов та шулайрак булырга тиеш иде... уйлавымча. Юк икән. Үз-үзенә шактый таләпчән, артык пафоссыз, сәламәт иронияле егет икән. Бер сүз белән, Лариса Гузеевача әйткәндә: «Все про себя понимает». Күңелем булды, ни әйтсәң дә – якташым бит. Әллә нинди глобаль темаларга сөйләшү дә түгел инде. Ләкин егетнең холкын бераз ачарлык...

– Мин синең белән үз гомеремдә беренче тапкыр сөйләшәм.

– Ярый, соңгысы булмасын.

– Җырларыңны тыңлыйм, әлбәттә, синең якташың бит инде мин. Эстрадага килгәнеңә ун елдан артты бугай инде?

– Казанга килгәнемә – 17нче ел. Казанга килеп укый башлагач, ике елдан сәхнәгә чыктым инде, җырлар яздырдым.

– Сольникларны да күп куйдың бугай?

– Тәәәк... (саный) санарга кирәк бит инде аларны... өчәү, дүртәү... 9 февральдә Татар филармониясендә булачагы бишенчесе була икән. Беренчесе 2010 елда булган иде.

– Бу синең егетлегең, уңганлыгың, эшкуарлыгың хакында сөйли инде – шулкадәр сольник...

– Бардыр инде. Аның бит авырлыкларын «ашаган белми, тураган белә».

– Нинди авырлыклары бар?

– Курку да бар, батырчылык итеп бетермәү дә, тәвәккәллек җитмәү дә.

– Тәвәккәллек җитмәсә, син ул концертларны кую түгел, көнен дә билгели алмас идең.

– Шундый халәттә булам мин – куркам, дулкынланам. Концерт узгач та саклана ул халәт.

– Менә сиңа кирәк булса. Карап торышка шактый кыю кыяфәтле үзең.

– Мин әле андый халәт иҗат кешеләренең күбесендә дип әйтер идем. Ул бит җаваплылыкны тоеп дулкынлану, планканы төшерүдән, кеше күз алдында ачылып бетә алмаудан курку. Җырларга, сәхнәгә чыгарга курку турында сүз бармый.

– Беренче концертыңны куйганда син әле бик яшь булгансың, берүзең тәвәккәлләп тотындыңмы?

– Ул чакта Фердинанд Хафизов ярдәм итте. Филармониядә ике көн булды концертлар. Заллар тулы иде. Ул концертны мәңге онытасым юк. Сәхнәгә чыгып бастым, җырлыйм, тез буыннары калтырый, үземдә коточкыч стресс. Шулкадәр дулкынландым, хәтта микрофонны тотып атып, сәхнәдән чыгып китәсем килде. Беренче җырны җырлап бетергәнче шул халәттә булдым.

– Беренче концертларыңа ук ике тулы зал җыйгансың. Билет сатучылар тырышлыгына гына кайтарып калдырып булмыйдыр моны.

– Беренче концертларга халык «аванс» белән килә ул. Аннан соңгыларына – беренче концерт тәэсирендә.

– Заллар тулырлык итеп кайда күренеп өлгергән идең соң шулай да?

– Төрле катнаш концертларда, хөкүмәт дәрәҗәсендәге чараларда, Илһам Шакиров, Салих Сәйдәшев, Рәшит Ваһапов исемендәге фестивальләрдә, «Татар моңы»нда...

– Бер әңгәмәдә син үзеңнең Президентның яраткан җырчысы булуыңны таныйсың. Моны бөтен дөньяга әйтә алу шулай ук егетлек, чөнки мондый «кыю ышаныч» бар кешегә дә ошамаска мөмкин бит. Дус бар, дошман бар дигәндәй...

– Дөресен әйткәндә, шулай булып чыкты да ул. Кайбер кешеләр башкачарак карый башладылар...

– Көнләшепме?

– Анысы да бардыр. Ләкин Президент алдында җырлау мәктәбе узу минем өчен бик мөһим мәктәп булды. Аның каршында бер сәгать буе микрофонсыз, баянга гына җырлау, беренчедән, минем кебек әле чагыштырмача яшь җырчы өчен сынау булса, икенчедән, тагын да зур җаваплылык йөкләде – мин бик күп ретро җырларны өйрәндем.

– Сезнең буында бик яхшы, талантлы җырчылар бар. Син дә шуларның исемлегендә. Исемлектәге башкаларны ата әле.

– Беренче урында – Филүс Каһиров, операга кыйбла тоткан Рузил Гатинны бик хөрмәт итәм, репертуарына бик җаваплы карый торган Рәяз Фасыйхов, Артур Исламов...

– Татарга музыкаль театр кирәклеге турында, бишьеллыкка бер булса да, сүз чыгып тора. «Кирәк, кирәк», – диелә, түгәрәк өстәлләр корыла, шакмаклы хатлар языла, сүз, сүз... Ләкин театр үзе түгел, әлегә аны ачарга теләүчеләр төзегән грамоталы концепция дә күзгә чалынмый. Берән-сәрән музыкаль проектлар бар-барын, бу да куанычлы хәл, ләкин театры – юк. Ә бәлки нәкъ менә сез – талантлы, белемле, эстрадада эшкуарлык дәрәҗәсен дә булдыра алган татар егетләре тотынырга тиешләр ул эшкә?

– Дәүләт тарафыннан ярдәмсез була торган эш түгелдер бу. Финанслар, эшне башлаучылар һәм алга таба алып барырлык көчләр кирәк. Безнең ул хакта егетләр белән сөйләшеп утырган бар. Уйлыйбыз, сөйләшәбез... Фикерләребез, планнарыбыз бар. Әлегә барын да ачасы, алдан «кычкырып» куясы гына килми.

– Ярый, әйтмә. Бу хакта уйлавыгыз, план корыгыз ук яхшы инде. Димәк, бу темага сез – уңышлы, «тук» җырчылар да битараф түгел.

– Ничек инде битараф буласың?! Минем, мәсәлән, фонограммага җырлаучылардан, теләгән бер кешенең сәхнәгә чыгуыннан зур канәгатьсезлегем бар. Бүгенге меңләгән «җырчы»ның күпмесе сыйфат таләбенә җавап бирә, нигә эстраданы күзәтеп торучы, таләпләр куючы орган, законнар юк? Лицензияләр белән эшләсәләр, бәлки, барысы да башкача булыр иде.

– Күп шау-шу кубарган «Үзгәреш җиле» проектында катнашкан санаулы башкаручылар арасыннан интернетта, социаль челтәрләрдә иң күп сүгелгәне син булдың. Белгәне, белмәгәне рәхәтләнделәр генә сине «яңача» «Ак калфак» өчен «тукмап». Тәнкыйть – мактау түгел, күңелгә сары май булып ятмый...

– Тәнкыйтьне сиңа битараф кеше әйтми инде, синең өчен борчылган кешеләр генә әйтә. Кайчагында бик ризалашасы да килми, анысы да хак, ләкин уйлый торгач, анализлый торгач, тәнкыйтьнең файдага булуын аңлыйсың. Дошманнарның мактавына караганда, сиңа битараф булмаганнарның дөрес тәнкыйте яхшырак. Венера Әхәтовна әйтә бит: «Мин ничә еллар җырлыйм, әле һаман җырларга өйрәнәм», – дип. Барыбыз да шулай. Камиллекнең чиге юк ич инде. Ә «Үзгәреш җиле»нә килгәндә – «Ак калфак»ны бит төрле стильләрдә җырлап, эшләп була. Бу очракта исә оештыручыларның җырга үз карашлары, планнары, фикерләре бар иде, мин шуны тамашачыга җиткерүче генә идем. План куелган иде – үтәргә кирәк. Ә ул җырны яңача башкару шулкадәр катлаулы булды. Анда бит өч куплетта өч төрле тональность, иң ахырдагы нота – югары «ля» иде. Җырлап бетергәндә пульсым 120ләр булгандыр. «Драйв» диләр инде ул халәтне.

– Их, белсәләр иде бу хакта сине сүгүчеләр, аларга таныш халәт булса иде ул...

– Мин быелгы концертымда «Ак калфак»ны төрле стильләрдә җырларга җыенам, халыкка кайсы күбрәк ошар. Яңа проектлар кирәк, алар бит җырчыларны гына үзгәртми. Күрдегезме күпме музыка белгече ачыкланды «Үзгәреш җиле»ннән соң, яңа тәнкыйтьчеләр пәйда булды. Файдага бит.

– Ничек уйлыйсың, җырчы гомеренең озынлыгы ни кадәр?

– Дөрес итеп яшәсәң, тавышыңны саклый белсәң, 70 яшьтә дә чыңлап тора ала ул тавыш.

– Җырчы булмасаң, нинди шөгыльләрең булыр иде икән?

– Мин җырчы булырмын дип килмәгән идем укырга. Укып чыккач, Теләчегә кайтырмын, мәдәният йортында эшләрмен дип уйлаган идем. Ә менә ничек килеп чыкты, җырчы булдым. Без мин бала чакта ук сәхнәдә йөри идек – «Музыкаль гаилә» дигән программа төзеп. Бабам музыка уен коралларында уйнарга үзлегеннән өйрәнгән, кубызлар ясаган кеше. Әтине авылдан җибәрмәгән, ә мин укырга киткәндә, бик хәерһах булды инде, куанып озатты. Бабам күптән түгел генә вафат булды.

– Улың, кызың бар. Татарча беләләрме?

– Начаррак беләләр шул. Минем өчен рәхәт әйбер түгел инде бу. Татар балалар бакчалары да татарча түгел бит аның. Өйдә дә, эшне «җиңеләйтеп», русчага күчелә.

– Үзеңнең җырлар язганың бармы?

– 30лап җырым бар.

– Әйбәт җырларымы соң?

– Арада яхшылары да бар инде... Элегрәк үзем җырлый идем аларны, хәзер ретро җырларга өстенлек бирәм.

«Тагын бер генә җыр җырлыйк әле...»

Әти-әниләрен иртә югалткангамы, Вәсилә Фәттахова туганнары белән аеруча җылы мөнәсәбәттә иде. Очрашканда, аларны еш телгә алды. 26 гыйнвар көнне яраткан җырчыбызның арабыздан китүенә бер ел була. Шул уңайдан апалары белән аны искә алырга булдык. Туган җанлы Вәсиләне алар бик сагыналар һәм әле дә булса кайтыр дип көтәләр...

Разыя Сираева:

– Вәсилә үлгәч, ятим иде, беркеме дә юк аның, диделәр. Юк, без аның туганнары – күпләрбез. Мөнәсәбәтләребез бик яхшы булды. Уфага нинди генә йомыш белән барма, һәрвакыт матур итеп каршы ала, озатып куя иде. Хастаханәгә барасы булса, анда йөртә, иренми иде. Аның йортына кунаклар килеп керсә, секунд эчендә өстәл әзерләп куя. Ите пешкән, шулпасы әзер. Токмачы алдан ук кисеп куелган. Аның кебек нәзек итеп токмач кискән кешене очратканым булмады. Районнан кем генә килмәсен, ул аларның һәркайсын зур кунак итеп каршы ала иде.

Җирне ярата иде бит ул. Югыйсә, уйлап карагыз инде: Уфага күченеп килгән яшь кыз ни өчен үзенә бакча участогы сатып ала?! Көчебездән килгәнчә ярдәм итәргә тырыштык. Ул кияүгә чыкканчы, килеп бәрәңгесен дә утыртыша идек. Күршеләре бакчасын сатарга булгач, аларныкын да сатып алды да бакчасы тагы да зурайды.

Тәмле телле иде Вәсилә. Нәрсә генә эшләмә, мактарга иренми иде.

Сеңлесе Әлфия үлгәнгә дә 10 ел булды. Ул да бик акыллы балакай иде. Мәктәптән кайтып дәресләрен, эшләрен эшли дә өй җыештырырга тотына иде. Табак-савытын кабат юып чыга, тузаннарны сөртә... Бер минут тик тормый. Тик торса да, китап укый иде. Китап укырга яратты. Ул бигрәк яшьли үлде – унҗидедә. Мәктәпне тәмамлап, институтка гына кергән иде.

Вәсилә белән күңелсез хәлләр булганда, мин кызым янында Новосибирскида идем. Әле декабрь башында (2015 ел) скайп аша сөйләштек. Казанга «атказанган артист» исемен алырга, бүләкләү тантанасына барырга җыена иде. «Разыя апа, нәрсә киярграә?» – дип сорады. Көн дә булмаса да, көнаралаш скайп аша «очрашып» тора идек. Казаннан кайткач та сөйләштек әле. Вакытыннан алда кызы туды, үзенең хәле начарайды. Илгиз кияү 4 гыйнвар көнне операция ясаганнарын хәбәр итте. Борчылдык, Аллаһыдан аның аякка басуын сорадык. Тагы бер операция, тагы... Аннан «Вәсилә үлде» дигән хәбәр килде. Кан басымым төшмәде, аякларым йөрмәс булды. Кызым: «Әни, Уфага кайтыйк, Вәсилә белән хушлашыйк», – диде. Юк, аякка басып булмады.

Кызганычка, соңгы елларда Уфага сирәк барылды. Ирем дә авырый, аны берүзен калдырып булмый. Вәсилә кияүгә чыкканчы, кунакка еш барыла иде. Барсам, бергәләп җырлый идек. Вәсилә матур итеп фортепианода уйный. Карыйбыз, сәгать төнге унбер. «Күршеләр уянмасмы?» – дим. «Разыя апа, тагы бер генә җыр җырлыйк әле», – дия иде...

Наилә Харасова:

– Мин – Вәсиләнең ике туган сеңлесе. Бер сыйныфта укыдык, бер музыка мәктәбенә йөрдек, бергә уйнап үстек. Очындырылып үсмәгән балалар без. Вәсилә яхшы шартларда үсмәсә дә, беркайчан да тормыштан зарланмый иде. Киресенчә, ямен, тәмен тоеп яшәде. Мин аның беркайчан да кешегә кычкырганын күргәнем булмады. Һәм безнең бер генә тапкыр да ачуланышканыбыз булмады.

Дәү әнисе аңа мәктәпкә кергәнче үк гармун бүләк иткән иде. Тиз арада уйнарга өйрәнде. Туганнар җыелышкан табыннарда Вәсилә уйнамый калмый иде.

31 декабрь – Вәсиләнең туган көне – иң матур бәйрәмнәрнең берсе булды. Аларның бер бүлмәле фатирында җыелышып, аның туган көнен, аннары Яңа елны бәйрәм итә идек. Ел да шулай иде. Вәсилә Уфага күченеп киткәч, бу көн моңсуланды, Яңа елны ансыз каршы алу бик күңелсез булды.

Быел мәктәпне тәмамлавыбызга – 20 ел. Мәктәп дигәч, сыйныф җитәкчесе хәтергә төшә. Ул Вәсиләне гел кыерсыта иде. Гел аңардан көлде, Вәсиләгә карата шулкадәр явыз иде. Шул күңелсез мизгелләр әле дә хәтеремдә саклана. Вәсилә йолдыз булып танылгач, аңа әйтәм: «Уңышка ирешкәнеңне сыйныф җитәкчесе белән бүлешәсең килмиме? Ачуын чыгар әле», – дим. Ул: «Юк инде, бер кешегә дә бер нәрсә дә дәлилләп йөрисем килми», – диде.

Без урыс телендә аралашып үстек. Милләтебез татар, башкорт булса да, туган телдә сөйләшми идек. Вәсилә татар телен җыр аша өйрәнде. Айдар Галимов төркеменә эшкә урнашканда да туган телендә аралашмый иде. Без әле дә татарча, башкортча белмибез, ә ул шәп сөйләшә иде.

Вәсилә белән һәр очрашу – бәйрәм иде. Аңа барасыңмы, ул синә кайтамы, зур табын әзерләп, барлык туганнар җыелыша идек. Ул һәркайсына ярарга тырыша иде, беребезне дә игътибарсыз, бүләксез калдырмый иде. Вәсилә дә китте, гаилә традицияләребез дә югалды.

Сания Гыймранова:

– Соңгы тапкыр Белорецкига кайтканда, ул никтер берүзе генә кайтты. Моңарчы гел Кәрим белән кайтты, каенанасын да ияртә иде. Ике көн миндә булып, барлык туганнарын күреп, хәлләрен белде. Хәзер генә аның шул рәвешле безнең белән хушлашырга кайтканын аңлыйм.

Соңгы тапкыр 29 декабрь көнне телефон аша сөйләштек. «Сания апа, шулкадәр чирлим мин, ашказаным яна», – диде. Аны-моны уйламадым да, үтә торган чирдер, дидем. Безнең өчен зур югалту булды ул. Үлемен авыр кичердек, хәзер җырларын тыңлау да бик кыен.

Ул бит тормышны нык яратты. Артыгы белән тырыш булды. Янындагы барлык кешеләрне мактап туя алмый иде. Кешене бүлдерми тыңлый белә иде. Тыңлап бетергәч, киңәшләрен җәлләмәде.

Әтисе дә, әнисе дә матур кешеләр булды. Гадиләр. Флүзә – төзүче, Рәзиф шофер иде. Әтисе ягыннан бар туганнары да татарлар. Камилә исемле искитмәле дәү әнисе бар иде. Аның исемен кызына куштырды да.

Вәсиләнең елын уздырырга иң олы апабызда – Рәкыя апада җыелышабыз. Бер ел үтте, әмма әле дә ышанып бетеп булмый. Табын артында утырганда, елмаеп, Вәсилә кайтып керер төсле...

Азалия ИСМӘГЫЙЛЕВА.

Салкын аңа нипачум!

Төмән егете Руслан Вахитов кышны бер кат майка белән шортыдан чыга. Безнең кебек, бүген урамда ничә градус суык икән, дип кызыксынып та тормый. Майкасы белән шортысын киеп, велосипедка атланып йөрүен белә. Ишегалдында торган машинасына сәлам генә биреп китә.

Руслан белгечлеге буенча инженер-механик, Төмән дәүләт авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлаган. Биш ел газ хезмәтендә инженер-механик булып эшли, әмма бу һөнәргә күңеле ятып бетмәгәч, педагогика университетына укырга керөп, физкультура укытучысы дипломын ала. Хәзерге вакытта Төмән өлкәсенең айкидо федерациясендә инструктор булып эшли. 12 ел инде айкидо дәресләрен алып бара.

– Элек велосипедта җәен генә йөри идем, 2013 елны кыш көне дә йөрергә булдым. Икенче елны инде «пуховик»ны салып, кышны бер кат футболкадан чыктым. Ә менә узган елны ирендердеме шунда, машинага күчеп утырдым. Гәүдә авырлыгым 13 килограммга артты. Болай булмый икән дип, быел кабат велосипедта йөрим. Урамда һава температурасы 25 градус салкын булганда да майкадан гына чыгам, әмма бернечә тапкыр кибетләргә кереп җылынып чыгарга туры килә.

– Чыныккан кеше булар, салкын тиеп авырып ятканың да юктыр инде.

– Бөтенләй суык тидергәнем юк дип әйтә алмыйм, вируслар мине дә читләтеп үтми. Әмма баш, тамак авырту, температура бер көндә бетә. Болар барысы да организмны чыныктыру белән бәйле. Сәламәт яшәү рәвеше белән 1997 елдан бирле кызыксынам. Аның төрле алымнарыннан файдаланам, үземдә сынап карыйм. Порфирий Ивановның чыныгу методикасы белән танышкач, тәнемне суыкка өйрәтә башладым. Параллель рәвештә спорт белән ныклап шөгыльләндем. Суыкта физик күнегүләр ясап тәнемне чыныктырсам, айкидо минем рухымны ныгытты. Контраст душның да файдасы бар. Аны сезгә дә киңәш итәм.

– Сәламәт туклануга да игътибар итәсезме?

– Баштарак ач тору методикасы белән кызыксындым. Бер көн. Аннары ике көн ач тордым. Акрынлап, организмымны шуңа өйрәттем. Үзәмә күрә рекордым да бар: егерме ике көн рәттән ач тора алам, җиде көн ашамый-эчми тордым. Вегетариан да булдым. Хәзер чи ризыклар белән генә тукланам. Киләчәктә фрукторианлык һәм сыек туклануга күчәргә җыенам. Ягъни ит, сөт ризыкларын гына түгел, яшелчә дә ашамыйсың. Җиләк-җимешне чи килеш кенә ашаячакмын. Сыек туклануга килгәндә, ул үз эченә продуктларны сыек килеш ашауны ала. Аңа аш, сок, смузи керә. Әлеге системалар эчке энергияне күбрәк бирә. Кеше организмының мөмкинлекләре дә, чыдамлылык запасы да чиксез, аны дөрес куллана белергә генә кирәк.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Төрмәдән качкан шикелле...

яки 30 ел тартканнан соң тәмәке ташлау тәҗрибәсе

Бу хакта берни дә язмам дигән идем. Ләкин социаль челтәрләргә хәбәр бирү белән, анда фикер уртаклашучылар табылды, тәкъдимнәрен, теләкләрен язып җибәрделәр. Һәм шул арада берничә гәзиттән тәмәке тартуга мөнәсәбәтемне сорап шалтыраттылар. Шуннан мин бу тема бөтенләй үк өметсез түгел икән бит әле, дигәнрәк фикергә килдем.

Марат КӘБИРОВ

ТӘМӘКЕ ТАШЛАУ – ӨЙРӘНЕЛГӘН ЭШ

Беренче тапкыр беренче сыйныфка укырга барганда ташлаган идем. Парта артыннан бөтенләйгә торып киткәнче кабат башларга туры килмәде. Дүртенчедәме-бишенчедәме укыганда, малайлар белән клуб артына чыгып берәр папирос пыскытырга маташып караган идек. Бәхеткәме, бәхетсезлеккәме – кабызган тәмәкене тартып бетерергә насыйп булмады, мәктәп директоры эләктереп алды. Директор – авылда нык абруйлы кеше, ул безнең әти-әниләрне дә укыткан. Без аңа курку катыш хөрмәт белән карый идек. Йөземә фонарь белән генә яктыртып карады да китеп барды. Әнигә әйткәндер инде дип куркып кына кайттым. Ул әйтмәгән булып чыкты. Болай булгач, мәктәп линейкасында алга чыгарып сүгәчәкләр икән дип көттем. Сүгүче булмады. Тагын нәрсәдер көтеп йөрдем. Берни әйтүче булмады. Бу юлы мине сүзсез генә тәрбияләделәр. Һәм ул, берсүзсез, әһәмиятле булды.

Тәмәке ташлау турында уйлагач, шул чакны хәтерләп, мәктәп директорын сагынып куйдым. Их, менә ул тагын фонаре белән яктыртып китсен иде кебек тоелды.

Өзлексез тарту стажы – 30 ел. Бу инде уен эш түгел. Утыз ел буена даими рәвештә башыңны гына сыйпап торсаң да, бу гадәткә әверелә. Кулларың үзеннән-үзе шул хәрәкәтне юксына башлый. Ә тәмәке – алай гына түгел. Тәмәкениктнең организмында никотин эшләп чыгару процессы туктала. Һәм тартуны ташлагач, кешенең организмы никотин таләп итеп бәргәләнә башлый. Шул сәбәпле, аны ташлау кыен. Монысы – киң таралган вариантларның берсе. Ә чынында кеше организмында тәмәке белән бәйле әллә нинди химик, физик, психик процесслар бара. Һәм тагы да төгәлрәк әйткәндә, галимнәр моның нәрсә икәнен үзләре дә аңлап бетерми. Ләкин бер нәрсә бәхәссез – тәмәкегә бәйлелек хасил була һәм ул тарту стажы белән бергә үсә бара. Американың наркоманияне өйрәнү институты (NIDA) белгечләре фикеренчә, тәмәкегә булган бәйлелек героин һәм опиатларга караганда да күпкә көчлерәк.

Тәмәкегә бәйлелекнең төп сәбәбен никотин белән генә аңлату дөрес түгел. Моның әле әллә күпме психологик төсмерләре бар. Әйтик, кайчан телисең, шунда көйрәтеп җибәрәсең (ireklelek иллюзиясе), сигаретны бармак очларында ничек телисең, шулай әйләндерәсең (манипуляция, башкалар белән идарә итү мөмкинлеге), синең янда бары тик тәмәке исенә түзә алучылар гына басып тора (үз орбитаңны чистарту), һ.б. аңасты мәрәкәләре. Нинди дер каһарманнарга, кумирларыңа охшарга тырышу феноменын да өстәсәң... Кыскасы, тәмәке тарту безнең эгоистик тойгыларны канәгатьләндерүнең дә бер ысулы булып тора.

pinterest.com

КИСӘТҮ: тәмәке сезнең сәламәтлеккә зыян сала!

Тартуны ташлау турында карар кабул итү – иң кыены. Бу хакта уйлау белән үк кеше организмының әллә нинди кисәкләре карышырга тотына. Үзеңне нинди дер бик мөһим нәрсәдән мәхрүм калгандай тоясың. Бәхетле кешеләр, әйтик, чыга да рәхәтләнеп тәмәке көйрәтә. Моннан гына алар үлмиләр дә, чирләмиләр дә. Җаннарына рәхәт булып кына кала. Ә син... Син ташларга... Юк инде, уйлама да!

Тәмәкенең зыяны турында күп сөйләнгән, күп язылган. Үпкә, йөрәк-кан тамыры авырулары, нәсел калдыру эшчәнлегенә зарары... Бер карасаң, каза күрми калган бер генә орган да булмый бугай. Тик без ул зыянны шундук тоймыйбыз, шундук тоймагач, зарарсыз дип уйлыйбыз.

Өстәвенә, бер штук тәмәке атны үтерергә сәләтле, дигән сантый сүзләр белән тәмәкениктнең күңелен юаталар. Әйтерсең тәмәке тартудан үлгән атлар адым саен очрап тора инде. Шундый ук уңыш белән без: «35 кап тәмәке К-700 тракторын ватарга сәләтле», – дип тә әйтә алыр идек. Чөнки бу тракторда – җиде йөз ат куәте.

Атлар белән хәл ничек торадыр, ә менә кешене үтерү өчен 60 мг никотин кирәк, диләр. Бер штук сигаретта 0, 3 -1,25 мг никотин булуын исәпкә алсак, бу – бер-бер артлы тартылган өч-дүрт кап тәмәке инде. Күләм ягыннан исәпләсәң, шулай. Ләкин никотин кеше организмында тиз таркала. Шуңа күрә бер-бер артлы хәтта ун кап тәмәке тартсаң да, үлүең икеле.

Тиз генә үтерми. Тиз генә чирләтми. Ә йөрәк, кан тамырлары, үпкә, җенес әгъзалары белән бәйле һәртөрле авырулар... алар инде кайдадыр еракта... кемнәргәдер... безгә бөтенләй таныш булмаган кешеләргә... килә торган, дөресрәге, килүе мөмкин булган... мифик күренешләр. Кеше табигате шулай төзелгән – ул чиргә ышанмый, барлыгын белсә дә, аның үзенә килүенә ышана алмый.

Нинди дер эшне эшләргә дәрт, илһам бирү төшенчәсен, кызыксындыру чарасын хәзер «мотивация» дип атыйлар бит инде. Менә шул, тәмәке тартуны ташлау өчен берни нди мотивация юк. Сәламәтлек турында әйттек инде. Башкаларны агулау... Дөресен генә әйткәндә, хәзерге заман кешесе башкалар турында уйламый инде. Үзенә ләззәт яки файда китерә торган гамәлдән тыелмый ул. Андый тормозы юк, ватылган, заман арбасының тәгәрмәче астында калган. Акча әрәм итү. Әлбәттә, бу күпмедер дәрәҗәдә ярдәм итә алыр. Ни генә әйтсәң дә, аена якынча 3-7 мең сум акча китә. Бу үзе үк бер кредит түләгән кебек. Ләкин безнең халык хәзер кредитка шулкадәр нык күнеккән, аңа плюс-минус бер кредит берни тормый. Гөнаһ... Бу хактагы сүзләрне безнең организм төрле фильтрлар аша, мең нәрчә ташламалар ясап кабул итә. Шул рәвешле бик озак санарга мөмкин булыр иде. Тартуны ташлау өчен берни нди мотивация, җитди кызыксындыру чарасы юк. Шуңа күрә иң кыены – карар кабул итү. Һәм ул иң мөһиме дә. Барысы да карарның ныклыгыннан тора. Шуңа күрә кеше ташлый дип яки кемгәдер ияреп ташламагыз. Бу сезнең шәхси ният булырга тиеш. Сроклар билгеләмәгез. Ташламалар ясау турында уйламагыз.

Син күнегелгән дөнья читлегеннән башка киңлеккә чыктың. Бу үзе үк синең өчен яңа күренеш, яңа тойгы. Бу гамәлгә керешүең өчен беркадәр шатлык та, горурлык та, җиңеп чыга алырмынмы дип дулкынлану да бар.

Ә иң зур тойгы – яңалык. Син башка дөньяда. Күнегелмәгәнчә яшәргә тиешсең. Тәпи басарга өйрәнгән бала белән дә тиңләргә мөмкин бугай. Шундый ук ихлас, шундый ук тырыш. Шундый ук аңгыра. Аңгыраеп йөрү биш-алты көн дәвам итә. Тира-як белән әлемтә начаррак эшләгән кебек, тиз генә аңлый да, карар кабул итә дә алмыйсың. Хис-тойгылар беркадәр тупасрак дип әйтимме инде... үткенлек юк... Нәрсәнедер перчатка белән тоткач, аны бар тулылыгында тоя алмыйсың бит. Тормышны кабул итү дә шул чамарак.

Урамга чыккач, куллар кесәгә үрелә – тәмәке, шырпы эзли. Берни дә тапмагач, үзләрен кая куярга, ничек тотарга белми азапланалар...

Матур гына эшләп утырган җирдән торып басасың да тәмәке тарту урынына омтыласың һәм исеңә төшә – ташладың ич. Ләкин ни дә булса эшләргә кирәк, берәр җимеш булса да кабып куясың. Организм тынычлана төшә, әмма берәздан әлеге хәл тагын кабатлана. Моның отышлы ягы бар – һәрбер җимеш, тартып керүдән тыелу – синең кечкенә җиңүең. Шул рәвешле син кеннән әллә ничә тапкыр үзеңне җиңүче итеп тоясың.

Ләкин бу хис әллә ни көчле ләззәт бирми. Гомумән, бернәрсәне дә бар нечкәлегендә тоя алмыйсың. Скафандр эчендә яшәгән кебегрәк тоеласың. Тизрәк аны салып ташлыйсың килә. Ә моның өчен бер сигарет җитәр иде.

Бәлки, кисәк ташларга кирәкмидер. Берәр ай буена дозаны киметә барырга кирәк булгандыр, шуннан соң гына бөтенләй ташларга. Бәлки, шулай итеп карарга дыр? Бүген берничәне генә тартам да... иртәгә бергә киметермен...

Менә шундый алдаткыч уйлар да килә башка. Бу очракта барысын да үзгәртергә кирәк. Көн тәртибен. Аралашкан кешеләрне. Гадәтләнгән юлларны. Берни дә тәмәке турында хәтерләтергә тиеш түгел.

Бераздан соң, тартуны ташлавыгыз турында белгәч, дусларыгыз һәм якыннарыгыз сезне төрлечә «сынап» карарга аяк. Кыстап, үгетләп, җайлап-майлап, мыскыллап... Бу һәркем белән була торган вакытлы күренеш һәм аңа әзер булырга кирәк.

Ихтыяр көче кирәк, диләр. Ерунда! Берни нди ихтыяр көче дә кирәкми, ул сиңа берничек тә ярдәм итә алмый һәм ихтыяр көченә исәп тотасың икән, мәңге ташлый алмыйсың. Чөнки ашау, эчү, эчәкләрне бушату һ.б. кебек организмның табигый ихтыяҗларын җиңә алырлык ихтыяр көче беркемдә дә юк. Ихтыяҗ көчен ихтыяр көче җиңә алмый. Тәмәке тарту да инде организмның табигый бер ихтыяҗына әверелгән.

КАРАШЛАРНЫ ҮЗГӘРТҮ КИРӘК

Иң мөһиме. Тәмәке тартмау ул нәрсәдәндер мәхрүм булу түгел.

Төн уртасында... Икмәк кирәк булса, түзәсең. Сөт кирәк булса, түзәсең. Хәтта нинди дер дару кирәк булса да аптекага соңгы чиктә генә, сыкрана-сыкрана гына чыгып керәсең. Ә тәмәкең бетсә, шундук чыгып йөгерәсең. Тугры кол шикелле. Якындагы кибет бикле булса, ерактагысына китәсең. Тапканчы эзлисең. Акчаң булмаса, урам буенда сорашып йөрисең. Бер штук тәмәке алып тартмыйча тынычланмыйсың. Ә беркадәр вакыттан соң тагын тартасы килә башлый.

Тарту – коллыкның бер төре. Хәтта кеше дә түгел, ә бармак башы чаклы җансыз бер нәрсә синең белән идарә итә. Тәмәке тартмау ул – нәрсәгәдер ия булу.

Шуңа күрә тәмәкедән баш тартуны югалту дип түгел, ә табыш дип кабул итәргә кирәк. Азатлык бу. Ә азатлык үзеннән-үзе килгән рәхәтлек түгел. Азатлык нәрсәдәндер баш тартудан башлана.

Калганнары шуның тирәсенә җыела.

Тәмәке тарту – өстәмә мәшәкать. Һич югында киенергә, урамга чыгарга кирәк. Бу билгеле бер вакыт саен кабатлана. Эсседә дә, салкында да, явымда да, давылда да. Кылны кырыкка ярырдай ашыккан чагында да. Гомумән, тәмәке тартучының тормышы һәрвакыт бер мәшәкатькә артыграк.

ТӘМӘКЕ ТАРТУ – ӨСТӘМӘ ЧЫГЫМ

100 сум булса да, 250 яки 200 булса да, кеше тәмәке сатып алачак. Иң аз дигәне дә аена 3 мең тирәсенә төшә. Бу акчага бассейнга яки спортзалга йөрергә мөмкин булыр иде. Вакытың да күңелле уза, файдалырак та.

Тәмәке тарту – өстәмә низаг. Урамга чыгып тормыйча гына баскыч мәйданчыгында тартасың икән, күрше хатыннарының мырлавын тыңларга кирәк. Өйгә кергәч, үз хатыныңның моң-зарын ишетәсең. Ул инде: «Тәмәкең бигрәк яман исле... бабайлар кебек сасып йөрисең...» – дип әйтү мөмкинлеген кулдан ычкындырмый.

Шул рәвешле, тәмәке тарту һәм ул тудырган бик күп проблемалардан көннән-көн котыла баруың ачыклана. Бу очракта вакыт синең файдага эшли. Син бу очракта төрмәдән качкан кеше шикелле – адым саен, минут саен коллыктан, тоткынлыктан ерагая барасың...

«Монафыйклар җәһәннәм утының иң аскы катында булырлар»

Коръән-Кәримнең «Ән-Ниса» («Хатыннар») сүрәсе, 145нче аятендә: «Монафыйклар җәһәннәмнең төбендә булырлар һәм аларга ярдәм итүче булмас», – диелә. Хәдисләрдән аңлашылганча да, элек сәхабәләр монафыйклыкның үзендә булуларыннан курыкканнар. Кемнәр алар монафыйклар һәм, гомумән нәрсә соң ул монафыйклык? «Өметләләр» мәчете имам хатибы Алмаз хәзрәт САФИНга без шул сорау белән мөрәҗәгать иттек.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Ислам галимнәре монафыйклыкны ике төргә: зур һәм кечкенә монафыйклыкка бүлеп карый. Беренчесе кешенең ышануы белән бәйле. Зур монафыйклык кылучы ул йөрәге белән иманның һәм исламның бер баганасына да ышанмый, ләкин үзенең дәрәҗәсен, байлыгын, эшен саклау өчен, тыштан мөселман булып кылана. Ул теле белән «Лә иләһә иллә-Ллаһ, Мухәммәдүн рәсүлуллаһ» дип әйтә, мөселманнар белән мәчеттә намаз укый. Ләкин ялгызы калса, ул бу гамәлләрнең берсен дә үтәми. Гадәттә, мондый монафыйклык ислам дине, мөселманнар көчәйгән вакытта барлыкка килә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.) Мәдинә шәһәренә күчкәч, ислам дине куәтләнә. Мөселманнарның көчәйгәнен күргәч, кабилә башлыклары Пәйгамбәр белән сугышып йөрми, үзләренең дәрәҗәләрен, вазифаларын саклап калу өчен, тыштан ислам динен кабул итәләр. Алар исә Аллаһы Тәгалә каршында кяфер булып санала, чөнки намаз укысалар да, аларның күңелләрендә иман юк. Алар Аллаһы Тәгаләгә дә, фәрештәләргә дә, пәйгамбәрләргә дә, Коръәнгә дә, кыямәт көненә дә ышанмыйлар. Әлеге кешеләр мөселманнарга кяферләргә караганда да күбрәк зыян сала. Кяферләр мөселманнарга тискәре карашын ачыктан-ачык белдерә. Ә боларның эчендәгесен белеп булмый, чөнки тыштан ул үзен мөселман дип атый. Шул сәбәпле мөселманнар аларның зарарыннан үзләрен саклый алмыйлар.

Кечкенә монафыйклык исә кешенең гамәлләре белән бәйле. Мөхәммәд Пәйгамбәр кайбер гөнаһларны монафыйклар гамәле диде. Бер хәдисендә ул: «Монафыйк кешенең галәмәте өчәү: сөйләсә – ялганлый; вәгъдә итсә – үтәми; әманәт тапшырылса, аңа хыянәт кыла», – дип әйтә. Мондый эшләрдән сакланырга кирәк, чөнки ул гамәлләр монафыйкларга гына хас. Икенче бер хәдистә ул: «Дүрт төрле сыйфат бер кешедә булса, ул – чын монафыйк. Әгәр дә анда шуларның берсе генә булса, ул шул сыйфат беткәнче монафыйк сыйфаты белән йөри», – ди. Әлеге дүрт сыйфат: әгәр дә аңа әманәт тапшырылса, ул аңа хыянәт итә, сөйләсә – ялганлый, килешү төзесә, аны боза, бәхәсләшсә, чикне узып, начар сүзләр сөйләп, ялган дәлилләр табып бәхәсләшә». Мөселман кешесе әлеге гамәлләрдән читтә торырга тиеш.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә монафыйклыкның башка сыйфатлары турында да әйтә. «Тәүбә» сүрәсе, 67нче аятьтә: «Монафыйклар гөнаһка өндиләр, изгелектән тыялар», – диелә. Чын мөселман, киресенчә, изгелеккә өнди һәм гөнаһлардан тыелырга чакыра. «Ниса» сүрәсенең 142нче аятендә шулай диелә: «Дөреслектә, монафыйклар Аллаһны алдамакчы булалар. Ләкин Аллаһ аларның үзләрен алдый. Әгәр дә алар намазга басса, аны ялкаулык белән укыйлар һәм гамәлләрен кешеләр күрсен өчен кылалар», – диелә. Намазларын һәм изге гамәлләрен Аллаһы Тәгаләдән әҗер-савап өмет итеп һәм җәннәтле булыр өчен түгел, ә кеше күрсен һәм мактасын өчен кылалар. Ягъни гамәлләрне рия белән – кеше күрсен дип эшләү ул – монафыйклар сыйфаты. Бу монафыйклыкның алда әйтеп үткән төре кебек диннән чыгармый, ә гөнаһ булып санала. Мондый сыйфатлар иманы зәгыйфь булган мөселманнарда да булырга мөмкин.

– Мөселман кызларының яулык ябуыннан көлүчеләр дә монафыйк саналамы?

– Ул гына түгел, ураза тотудан, намаз укудан, башка дини гамәл-йолалардан көлү зур монафыйклык санала. Бу аларны диннән чыгара торган сыйфат. Аллаһ Тәгалә әйтә: «Әгәр дә алардан диннән көлүләре турында сорасаң, алар әйтә: «Без бары тик фикер генә алыштык һәм шаярдык». Син әйт: «Әллә сез Аллаһның аятьләреннән һәм илчесеннән көлдегезме? Акланмагыз! Иман китергәннән соң сез кяфер булдыгыз» (Тәүбә: 65-66).

– Динне белеп бетермәве аркасында көлсә...

– Монысы диннән чыгармый, ә гөнаһ санала.

– Үзе намаз укып, хәләл булмаган казылык ашаса...

– Бу хәрам түгел, хәләл, аны ашау гөнаһ түгел дип ашаса, диннән чыга. Ә гөнаһ икәнен белеп, нәфесен тыя алмыйча ашаса, гөнаһлы мөселман була.

– Ураза тотмыйм, намаз укымыйм, әмма Аллаһыга ышанам диючеләр кемнәр була?

– Алар монафыйк түгел, иманнары гына зәгыйфь, динне белеп бетермиләр. Шуңа да иманны ныгытып, туры юлга басарга, Аллаһы Тәгаләгә якынаерга кирәк.

Февраль аена намаз вакытлары

Көн	Көн исеме	Сәхәр тәмам	Мәчетләрдә укыла	Кояш чыга	Зәвәл	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ясту намазы
1	Чәр	05:28	06:07	07:37	11:57	12:00	14:26	16:17	18:04
2	Пән	05:27	06:05	07:35	11:57	12:00	14:28	16:19	18:06
3	**Җом**	**05:25**	**06:03**	**07:33**	**11:57**	**12:00**	**14:30**	**16:22**	**18:08**
4	Шим	05:24	06:01	07:31	11:57	12:00	14:32	16:24	18:10
